• ВАКЫЙГА •

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА ЯЗЫЛ

*2019 елның 1 яртысына язылу бәясе 132 сум. Язылу индексы П4333*

• СӘЛАМӘТЛЕК •

ДӨРЕС ТУКЛАНУ – СӘЛАМӘТЛЕК НИГЕЗЕ

*4 бит*

• МИНБӘР •

КӨНДӘЛЕК ЭШЛӘР ГЫЙБАДӘТ БУЛА АЛАМЫ?

*10 бит*

• ЯШЬЛӘР ГАЛӘМЕ •

«ЯШЬ ВӘГАЗЬЧЕ» БӘЙГЕСЕ ИГЪЛАН ИТЕЛӘ

*12 бит*

*№ 11 (280)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *сафәр – рабигыль-әүвәл 1440*

*ноябрь, 2018*

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Болгарда Мәүлид Ән-Нәби узды












*Дәвамы 8 биттә*

# Коръән тәфсирләре әзерләнә

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә татар һәм рус телләрендә Коръән тәфсирләрен басмага әзерләү эше тәмамлануга якынлаша. Проект Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә тормышка ашырыла.



Рус телендә тәфсир бүгенге көндә тулысынча әзерләнеп, соңгы төзәтмәләр кертү этабында тора. Мөхәррирләр әлеге эшне өч ай эчендә башкарып чыгар, дип көтелә. Рус телендәге тәфсир өстендәге эш алты ел дәвамында алып барылды.

Татар телендә тәфсирнең өчтән икесе эшләнгән. Ягъни мөфтият белгечләре алдында утыз җүзнең тагын 7-сен әзерләү максаты тора. Шунысы игътибарга лаек, Коръәннең татар теленә тәрҗемәсен китап рәвешендә бастыру алдыннан, аны киң җәмәгатьчелеккә күрсәтү күздә тотыла. Шул рәвешле тәфсир буенча халык белән фикер алышу, кызыксынган белгечләрнең тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен җыеп өйрәнү һәм аларның иң уңышлыларын тәфсир текстында файдалану ниятләнә. Бүгенге көндә Коръәнне татар телендә тәфсирләү проектында 6 тел һәм дин галиме эшли. Хезмәт 2019 ел башында басылып чыгачак, дип көтелә.

– Коръән тәрҗемәсен әзерләгәндә иң авыры – гарәп телендәге сүзләрнең мәгънәсен аңлатырдай хәзерге заман татар телендәге сүзләрне табу, – дип ассызыклый әлеге эштә катнашучы дин белгече, нәзарәтнең шәригать юнәлеше җитәкчесе Булат хәзрәт Мөбарәков.

Кәлам Шәрифне басмага әзерләү һәм Коръәнне өйрәнү буенча Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте зур эш башкара. Әлеге эшнең нәтиҗәсе булып Коръән нәшер итү генә түгел, аны халыкара дәрәҗәдә тану да торды: 2016 елда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чыгарган Коръәннең яңартылган версиясе 2017 елда Сүриянең Вакыфлар министрлыгы каршындагы Коръән Кәрим эшләре буенча Югары комиссия тикшерүен уңышлы узды. Нәтиҗәдә, Казанда басмага әзерләнгән һәм нәшер ителгән Кәлам Шәриф халыкара стандартларга туры килү турында таныклык алды.

■ dumrt.ru

# Бөтендөнья «Хәләл» советы ТР «Хәләл» стандарты буенча Комитетының сертификатын озайтты




2018 елның 28-30 октябрь көннәрендә Истанбулда (Төркия) Бөтендөнья «Хәләл» советының (Word Halal Council) 16 нчы Генераль Ассамблеясы узды. Аның эшендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча Комитет та катнашты. Халыкара оешма утырышы кысаларында ТР мөселманнары Диния Нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча Комитетына WHC сертификаты озайтылып тапшырылды. Документ Ассамблея утырышларында тавыш бирү һәм аның эшчәнлегендә катнашу хокукын бирә. Шул рәвешле, әлеге абруйлы оешманың сертификаты Комитетның халыкара дәрәҗәдә танылуына дәлил булып тора. Беренче тапкыр WHC әгъзасы булып Комитет 2014 елда сайлана.

Шунысын билгеләп узарга кирәк: ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты Ассамблея йомгаклары буенча Бөтендөнья «Хәләл» советының шаһәдатнамәсен алуга ирешкән бердәнбер Россия вәкиле булып калды.

■ dumrt.ru

# «Аурупа илләренә толерантлыкка Россиядән өйрәнергә киңәш итәр идем»

15 ноябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Бельгиядән килгән «Almolu S.A.» иҗат төркеме җитәкчесе Пьер Пирард белән очрашты. Ул «Без» дип исемләнгән проект өчен документаль фильм әзерли. Бу проектны гамәлгә ашыру кысаларында Пирард әфәнде, дини вәзгыятьне өйрәнү максаты белән, Босния, Ливан, Иран кебек илләрдә булган. Ул китергән мәгълүматларга караганда, бүген Бельгиянең үзендә 60 меңләп мөселман яши.

Бельгия кунагын Татарстандагы дини вәзгыять, күпсанлы конфессия вәкилләренең үзара килешеп, дус яшәве гаҗәпкә калдырган. Иң беренче чиратта, Пирард әфәнде мөфтидән республиканың моңа ничек ирешә алуы хакында кызыксынды. Камил хәзрәт сүзләренчә, җәмгыятьтә исламга карата тискәре караш бетсә, мөселманнар үзләренең чын традицияләрен, гореф-гадәтләрен үтәп яшәсә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең Сөннәте турында онытмаса, алар беркайчан да үзенең күршесенә зыян китермәячәк.

Татарстан мөселманнары исламның хакыйкый кыйммәтләрен һәм традицияләрен ничек саклый дигән сорауга җавап биреп, Камил хәзрәт республикада сыйфатлы дини белем алу һәм аның дәрәҗәсен күтәрү өчен барлык шартлар тудырылуын билгеләп узды. Күп баскычлы ислам мәгариф системасы татарстанлыларга туган җирләрендә белем алу, Россия һәм татар дини мирасын тирәнтен өйрәнү мөмкинлеген күз уңында тота. Шул ук вакытта Камил хәзрәт Аурупа илләрендә башка дини вәзгыять булуын һәм моны исәпкә алып, конфессияара мөнәсәбәтләрнең башка моделен формалаштыру кирәклеген ассызыклады.

Төрле дин әһелләре арасындагы мөнәсәбәтләр дә Бельгия кунагында зур кызыксыну уятты. Камил хәзрәт Россиянең Динара советы эшләвен, үзенең дә шушы советның әгъзасы булуын әйтте. Ул шулай ук митрополит Феофан белән теологик сораулар хакында сөйләшмәүләрен билгеләп узды, чөнки хезмәттәшлек таләп ителгән башка бик күп мәсьәләләр бар.

Әңгәмә барышында Татарстан мөселманнары башлыгы бүгенге җәмгыятьтә әхлакның түбән тәгәрәве сәбәпләре буенча да фикерләре белән уртаклашты: «Кызганыч, бүген кешеләргә төп «вәгазь»не хайпта рейтинг ясарга омтылган ММЧ укый».

Камил хәзрәт билгеләп узганча, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дустанә конфессияара мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча тәҗрибәсе Россия төбәкләрендә генә түгел, чит илләрдә дә кызыксыну уята: мөфти Аурупа Советы, БДБ, «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме мәйданчыкларында чыгыш ясады.

«Гомумән алганда, Аурупа илләренә толерантлыкка Россиядән өйрәнергә киңәш итәр идем, – дип нәтиҗә ясады ул. – Әгәр мөселманнар үзләрен җәмгыятьнең тулыканлы әгъзалары итеп тойсалар, алар, Бөек Ватан сугышы елларында СССР мөселманнары кебек, үзләре яшәгән дәүләтне саклаячак».

Очрашу ахырында Пьер Пирард мөфтигә очрашу мөмкинлеге өчен рәхмәт белдерде. Камил хәзрәт, үз чиратында, кунакка төрле ил мөселманнары тормышы белән кызыксынуы өчен рәхмәт әйтте. Шулай ук аны Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуга багышлап билбау көрәше буенча Халыкара турнирга чакырды.

■ dumrt.ru

# «Азан»га – биш ел

Биш ел дәвамында «Азан» радиосы Ислам кыйммәтләрен яктыртып, Идел буе регионында бердәнбер мөселман радиостанциясе булып тора.

2013 елда Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин инициативасы белән, үз эшен «Азан» мөселман интернет-радиостанциясе башлап җибәрде. Радио киң җәмәгатьчелеккә динебезнең хак кыйммәтләре белән беррәттән, татар халкы мәдәнияттен һәм татар теленең байлыгын җиткерүне үзенә максат итеп куя.

2018 елның сентябрь аеннан башлап, «Азан» радиосы тулысынча татар теленә күчерелә башлады. Шуңа бәйле рәвештә яңа тапшырулар чыгарылды. Укучыларыбызны бу тапшыруларның эчтәлеге белән таныштырып китәргә телибез:

• «Бәхет тулы йорт» – Исламда гаилә дәресләре; эксперт – Казан шәһәренең «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, алып баручы – Илмир Хәбибуллин;

• «Миһербанлы җаннар» – «Зәкят» хәйрия фонды белән берлектә әзерләнә торган тапшыру. Әлеге программада фондның күптөрле проектлары турында сөйләшәбез. Тыңлаучыларга һәр шимбә көн кайсы баланы сәламәтләндерүгә матди ярдәм җыелып бетүе һәм кемгә ярдәм җыю башлап җибәрелүен игълан итәбез. Якшәмбе кабатлау;

• «Таян Аллаһка» – дини-фәлсәфи шигърият, мөнәҗәтләр, бәетләр һ. б. яңгырый;

Соңгы ике айда «Азан» радиосы студиясендә Фәүзия Мөхәммәтова, Ленар Шәех, Әлфия Ситдыйкова, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рифат Сәлах, Булат Ибраһим, Гөлнур Корбанова, Алмаз Мансуров, Лилия Сәлахетдинова һ. б. шагыйрьләрнең иҗат җимешләрен яздырдык;

• «Күңелдән күңелгә» – Җәлил хәзрәт Фазлыев, Илдус хәзрәт Фәизов һ. б. күренекле дин әһелләребезнең вәгазьләре;

• «Көндәлек догалар» тапшыруының күпсанлы яңа чыгарылышлары әзерләнде. Монда көн саен кирәкле догалар: Коръәннән, сөннәттән алынган һәм пәйгамбәрләр кылган догалар яңгырый;

• «Сак булыгыз! Секталар!», «Хәбәрдарлык афәттән саклар» кебек антитеррористик тапшырулар эфирда көненә берничә мәртәбә яңгыратыла.

Шулай ук эфирга чыгарылуга «Иман тәме» (дини аудиокитаплар форматында әзерләнгән Ислам дине нигезләре тапшыруы; диктор: Фәнис Җиһанша), «Гыйбадәттә сәгадәт» (тәһарәт һәм намазга өйрәтү; диктор: Ленар Хамматов), «40 хәдис» (ИмамӘн-Нәвәви туплап калдырган Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең 40 хәдисе һәм аңа шәрехләр; лектор: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме, Казан шәһәренең «Зәңгәр» мәчете имам-хатыйбы Зөлфәт хәзрәт Габдуллин); «101 вәгазь» (Татарстан Республикасы һәм, гомумән, Россия Федерациясе авыллары һәм шәһәрләре мәчетләренең имам-хәзрәтләре вәгазьләре).

Шуны да әйтеп үтү кирәк: татар телен саклап калу һәм үстерүгә юнәлтелгән тапшыруларга да радиобызда зур игътибар бирелә. Мисал өчен, киләчәктә «Миллият сүзлеге» тапшыруын булдыру максатыннан, Татарстан китап нәшрияты белән килешенү төзелде.

Ә яңа елдан тыңлаучыларыбызны тулаем үзгәртелгән, яңа тапшырулар җәдвәле белән сөендерергә ниятлибез, ин шә Аллаһ. Шуңа бәйле, яңа тапшырулар исемлеге болар белән генә чикләнми әле. Бүгенге көндә радионың яңа сайты эшләнеп килә.

«Азан» радиосын radioazan.ru сайтында һәм Play Market (Android платформасындагы смартфоннар өчен) яки App Store'дан (IPhone'нар өчен) йөкләп алынган "АЗАН" радиосы кушымталары аша тыңларга мөмкин.

Барлык сораулар, фикер-теләкләр, тәнкыйть һәм хезмәттәшлек тәкъдимнәре 8 (843) 598-09-43 телефон номеры һәм radioazan@mail.ru электрон тартмасы аша кабул ителә.

Шулай ук ВКонтакте, Instagram социаль челтәрләрендә безнең белән элемтәгә керергә һәм яңалыкларны күзәтеп барырга була.


■ **Алия Миәссәрова, «Азан» радиосының баш мөхәррире**

# «Хозур ТВ» гаилә кыйммәтләре сагында

«Хозур ТВ» мөселман телеканалы барлык теләүчеләрне уникаль проект геройлары булырга чакыра: ул әти-әниләр һәм аларның балалары арасында мөнәсәбәтләр турында – «Үзеңә юл». Тапшыру барышында бала белән әти-әниләр арасында килеп туган каршылыклар һәм аңлашылмаучанлыкларны чишәргә алып баручы – аспект типологиясенә нигез салучы Булат Мостафин булыша. Ул яшүсмер фикерләвенең көчле якларын ачыкларга һәм аны нинди юнәлештә үстерергә кирәклеген күрсәтергә ярдәм итәчәк.

Телевизор караучылар тапшыруны һәр атнаның шимбәсендә «Хозур ТВ» каналында карый алалар. Моннан тыш, тапшыруның чыгарылышларын huzurtv.ru сайтында «Үзеңә юл» тапшырулары архивларында табарга, шулай ук YouTube сайтының «Хозур ТВ» каналында карарга мөмкин.

Тапшыруда катнашу өчен «Үзеңә юл» тамгасы белән tv@huzur.ru почтасына хат язарга кирәк.



# Дөрес туклану – сәламәтлек нигезе



Бүгенге көндә вакыт аз дип әйтәбез. Яшәү ритмыбыз тизәйгәннән тизәя бара: каядыр чабабыз, ашыгабыз. Шуңа күрә ашауга да безнең игътибар кими барадыр. Пицца, фаст-фуд ише әйберләр аш кебек ризыкларны кысрыклый да башлады кебек. Шул ук вакытта интернетта да, телевидениеләрдә дә дөрес яшәү рәвешенә багышланган бик күп программалар барлыкка килә. Тиз генә капкалап алуның зыяны да тиз барлыкка килә, организмның эшләү рәвеше бозылуга китерә дигән фаразларны еш ишетергә туры килә. Моның чыннан да шулаймы икәнен белер өчен без гастроэнтеролог ***Айрат Зиятдинов*** белән әңгәмә кордык.

**– Әссәләмү галәйкүм, Айрат Илдусович. Пациентларыгыз сезгә нинди авырулар белән ешрак киләләр? Бүгенге көндә мәктәп яшеннән үк фаст-фуд кебек әйбер ашап үскән кешеләрнең ашказаны авыртулары да иртәрәк чыга аламы?**

– Вәгаләйкүмүссәлам. Бу сорауда берничә мәсьәләне бүлеп карап булыр иде. Фаст-фудны гына алыйк: бүгенге көндә аның тирәсендә күп сораулар йөри. Фаст-фуд белән тукланырга ярыймы? Аның белән туклануның нинди начар яклары булырга мөмкин? Фаст-фуд инглиз сүзе: fast – тиз, food – ризык, ашамлык дип тәрҗемә ителә, ягъни тиз генә ашап алу, бездә аны капкалап алу да диләр. Фаст-фуд зыянлымы әллә юкмы? Безнең күбебез иртә белән үзенә бутерброд ясап ашарга гадәтләнгән. Бутерброд – ул үзе дә тиз генә ясала торган, без алдарак әйткән «тиз ашау»га карый торган ризык. Бу очракта бутербродта кулланылган ризыкларның сыйфатыннан карарга кирәк. Шулай итеп, бутерброд ясадыгыз, ди. Шул бутербродны аяк киемен кигән вакытта чиратлашып, ашыга-ашыга ашыйсыз икән, әлбәттә, бу зыян гына була. Әмма өстәл артына утырып, башта су эчеп, аннары яхшы итеп чәйнәп, ашыкмыйча гына ашасагыз, бу очракта зыяны булмаячак, ин шә Аллаһ.

**– Дөрес туклану ничек булырга тиеш?**

– Аерым бер авырту белән авырган кешеләрне исәпкә алмаганда, гади кеше өчен дә дөрес туклану мәсьәләсен элек-электән өйрәнеп килгәннәр. Ни өчен авыру кешеләрне дим, чөнки кайбер кешеләр төрле ашказаны авыртулары белән авырый алалар. Алар өчен махсус диеталар барлыкка китерелгән. Андый авыртулар бик күп һәм һәр авыруга үз диетасы да каралган. Әмма саусәламәт кеше шушы хасталарны булдырмас өчен, гадәти көнкүрешендә дөрес тукланырга тиеш. Бу мәсьәләгә электән үк кызыксыну зур булган. Диетологлар эшче сыйныф өчен бер төрле меню, акыл хезмәтендә булганнар өчен икенче төрле меню уйлый торган булганнар. Бүген дә шулайрак бүлеп карасак була. Мәсәлән, аксым. Акыл хезмәтендә булучыларга 80-100 грамм аксым тиешле, шуның кадәр үк май да кирәк. Үсемлек мае да, хайван мае да күз алдында тотыла. Шулай ук 400-500 грамм углеводлар кирәк. Аксым – төзүче матдә, майлар – энергия өчен кирәк, углеводлар шулай ук теге яки бу эш өчен кирәкле энергия һәм запаслар бирә. Шуңа карап, бу матдәләр булган ризыклардан үзеңнең менюны барлыкка китереп була. Кем нәрсә ярата инде. Кемдер балык, кемдер тавык һәм башка төрле ризыклар яратырга мөмкин. Ул шулай булырга тиеш тә: ашаганнан рәхәтлек алырга кирәк. Шул вакытта аның бәрәкәтен тоеп була.

Әйе, элек кайбер халыклар ашар өчен генә яши торган булганнар. Ягъни, ризык үзенә күрә бер культ булып торган. Без хәзер яшәр өчен ашау турында сүз алып барабыз. Боларны истә тотып, дөрес туклану – кирәкле мадтәләр кергән ризыклардан һәм үзеңә ошаган, үзең яраткан ризыклардан файдалану дип әйтсәк тә була.

**– Ягъни диетологлар шушы күрсәткечләрдән чыгып, кешегә теге яки бу менюны тәкъдим итәләр дип әйтсәк буламы?**

– Әйе, һәм бу дөрес юл. Кешенең нинди хезмәт башкарганына карап, тормыш режимын истә тотып ясалган меню яхшырак. Диетологлар, мәсәлән, һөнәргә карый. Кеше спорт белән шөгыльләнсә, димәк ул күп хәрәкәтләнә, шуңа да аңа бер төрле ризыклар булачак һәм кирәкле күләме дә күрсәтелачәк. Ә инде офисларда компьютер артында утыручыларга бүтән төрле меню кирәк булачак. Акыл хезмәтендә булучылар азрак хәрәкәтләнә, шуңа хәрәкәт өчен энергия күп кирәкми дигәнне аңлата. Боларның барысын да истә тоту, әлбәттә, яхшыга гына илтә.

Бүгенге көннең тагын бер проблемасы – гиподинамия. (Гиподинамия – организмның функциональлеге кимүе. Кан әйләнеше, сулау, ашкайнату системасы һәм терәк-хәрәкәт аппараты эшчәнлеге бозылу. Аз хәрәкәтчәнлек аркасында мускулларның кыскару көче кимүе). Аллаһыга шөкер, бүгенге көндә күп кеше фитнес залларына йөри башлады. Бу бер яктан бик әйбәт күренеш. Әмма анда йөргән кешеләргә бер киңәшем бар: фитнес тренерлар белән әйбәтләп сөйләшергә кирәк. Туклану, тренировка – болар барысы да көйләнгән булырга тиеш. Аерым диетологлар белән дә киңәшләшеп алу зыян итмәс.

**– Ислам динендә ашар алдыннан су эчеп кую, җиләк-җимешне ашларга кадәр ашау гадәте бар. Бу Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре белән дә раслана. Медицина моңа карата нәрсә дип әйтә?**

– Ашар алдыннан су эчү, дөрестән дә, бик кирәкле нәрсә. Мин аны үземнең пациентларыма да әйтәм. Бигрәк тә мөселман кардәшләр күренергә килгәндә, аларга бу хәбәрне җиткергәч, алар икеләтә куаналар. Беренчедән, Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәллам шулай дип әйткәнен алар болай да белә. Икенчедән, табиб та шулай дип әйтә. Әмма Пәйгамбәребез хәдисләреннән дә ерак булган кешеләр моның турында беләләр. Мәсәлән, Аурупа илләренең кафе-рестораннарында иң башта су китерелә. Кеше, үзенең ризыгын көткәндә, акрынлап су эчә тора. Болар – дөньяви дәүләтләр, әмма шушы канунннарга таяналар, чөнки медицина да шулай куша. Һәм җиләк-җимеш турында әйтеп үттегез. Бу медецина ягыннан да шулай: мин үземнең пациентларыма җиләк-җимешне авыр ризык ашаганчы ук ашап куярга кушам. Ни өчен соң җиләк-җимешне ач карынга ашарга кирәк? Беренчедән, аларда булган фруктоза организм белән тиз үзләштерелә. Гади тел белән әйткәндә, баш миендә туклану үзәге бар. Һәм бу очракта да, организм аңа ашказанына ризык керде дигән сигналлар җибәрә башлый. Ашыйсы килү кими һәм бу кешене күбрәк ашап җибәрүдән саклый. Икенчедән, авыр ризык ашаганнан соң, десертка җиләк-җимеш ашау болай да дөрес саналмый. Ул, әлбәттә, безнең җәмгыятьтә киң таралган күренеш, әмма бик үк дөрес күренеш димәс идем. Күз алдыгызга китерегез, бер савытта җылы ашау. Кеше тәне температурасы кебек 36-37 градус саклана. Хәзер аның өстенә берничә виноград, берничә мандарин һәм шуның ише әйберләр куеп чыгыйк. Берничә сәгатьтән җиләк-җимеш газлары бүленә башлаячак, чөнки җылыда сакланалар. Нәкъ шулай ук кеше белән дә була ала. Авыр ризык өстенә кергән җиләк-җимеш, берничә сәгатьтән, яки иртә беләнгә төрле газлар бүлеп чыгаруга китерә. Бу үз чиратында кешене дискомфортка кертә, ул ашказанында чәнчүләр тоя башлый. Һәм бу ашкайнату системасының үзгәрүенә дә китерә.

**– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү.**

– Аллаһы Тәгалә бүләк иткән тәнебезне саклыйк. Бу, иң беренче чиратта, безнең үзебезгә кирәк икәнен онытмыйк. Вәгаләйкүмүс-сәлам вә рахмәтулаһи вә бәрәкәтүһү.

■ **«Хозур ТВ»**

# Бала һәм гаилә бюджеты

Гаилә мәсьәләләрендә иң мөһимнәренең берсе – мөгаен, керем һәм чыгымнарның исәп-хисабы. Алдан хәстәрен күргән гаиләләр үзләренең керем һәм чыгымнарына һәрвакыт исәп-хисаб алып баралар. Әҗәтләргә (бурычка) кермәс өчен алар нинди әйберләргә күпме акча сарыф итәчәкләрен беләләр, чөнки бурычка керү кемгәдер бәйле булуга һәм гаиләдә тынычлык югалуга китерә.

Кызганыч, керем һәм чыгымнарның исәп-хисабы алып барылмаган яки бу мәсьәләдә игътибарсыз булган гаиләләрдә без үзгә бер картина күрәбез: акча уңга-сулга сарыф ителә. Гадәттә, мондый гаиләләр акрынлап бурычларга баталар, өйдән бәрәкәт китә, уртак юаныч, шатлык та калмый. Ир һәм хатын арасында проблемалар туа: ирнең дәрәҗәсен төшерү, арада мөнәсәбәтләр салкынаю. Әлбәттә, күп сарыф итеп тә, мондый аяныч хәлләр белән очрашмаган гаиләләр дә бар. Шунысы мөһим, кеше гаилә бюджетын алдан күреп планлаштыруның барлык чыгымнардан һәм акча таратып, мизгел генә булган рәхәтлектән кадерлерәк икәнен белергә тиеш.

Имам Садыйк: «Әгәр Аллаһы Тәгалә берәр йортка бәхет теләсә, ул гаилә әгъзаларын дөнья эшләрендә алдан күрүчән итәр», – дип әйткән.

Гаилә бюджеты белән дөрес идарә итү өчен иң элек ир белән хатын арасында үзара аңлашучанлык булырга тиеш. Алар икесе дә мәгънәсез (кирәксез) чыгымнар гаиләнең финанс хәлен какшатачак икәнлеген аңларга тиешләр. Икенчедән, бу мәсьәләдә һәрбер гаилә әгъзасының, шулай ук балаларның да ярдәме кирәк. Балалар акчаның җиңел юл белән табылмавын, әти-әнинең тир түгеп, гаиләне тәэмин итү өчен тырышуларын, хезмәт итүләрен (ана кеше өйдә хуҗабикә булса да) аңларга, белеп торырга тиешләр. Әти-әни булмаса, аларның теге яки бу чыгымнарын каплаучы булмаячагын аңлау зарур. Әти-әни балаларга гаиләнең мөһимрәк булган чыгымнары турында белгертергә тиешләр. Кагыйдә буларак, бу торак-коммуналь хезмәт буенча түләүләр, азык-төлек, киемсалым, дарулар һ. б.

Беренче дәрәҗәдәге чыгымнар уртак хаҗәтләр өчен, икенче дәрәҗәдәге – шәхси, ә бары тик алардан соң гына, калганнарына. Алдан күреп һәм планлаштырып, үзара аңлашып яшәгән гаиләләрдә бу эш әнә шулай башкарыла.

Әти-әни балаларының теләкләрен канәгатьләндерү өчен үз-үзләре турында онытырга тиеш түгелләр. Барлык нәрсә һәм иң яхшысы аларга дип тырышкан очракта бала көйсез, кире була һәм кылган яхшылыкның да кадерен белми үсә. Гаиләдә гаделлек һәм тигезлек булырга, һәрбер гаиләнең чыгымнары аның керемнәренә туры килергә тиеш.

Балаларның теләкләрен гаилә бюджетыннан чыгып канәгатьләндерергә кирәк. Балалар үзләрен тулы гаилә әгъзасы санап, бу гаилә өчен җаваплы итеп хис итәргә тиешләр. Баланың бары тик үзе турында уйлап, башкаларны онытырырга хакы юк. Балалар – үзләре дә булачак әти-әниләр, шуңа да аларны кечкенәдән үк булганга шөкер итәргә, сакчыл карарга һәм исраф итмәскә өйрәтергә кирәк. Гаилә акчасын уңга-сулга туздырса, ул үскәч тә шундый булачак. Бу хәлне хәтта бар яктан җитеш гаиләләрдә дә рөхсәт итәргә ярамый. Хәлле гаиләдә ата-анага балаларына барлык кешеләрнең дә бер үк дәрәҗәдә яшәмәүләрен һәм байларның ярлыларга, тормыш шартлары авыр булганнарга ярдәм итәргә кирәклеге турында аңлатырга кирәк. Ә тормыш шартлары авыррак булган гаиләләрдә әти-әниләр гаилә бюджеты белән сакчыл идарә итәргә һәм беркайчан да балаларга зарланмаска, киресенчә, аларны якты һәм матур киләчәккә өметләндерергә тиешләр.

Балалар инде мөстәкыйль рәвештә эшли алырлык яшькә җиткәч, әти-әни аларны эшкә өндәргә мөмкин. Башка гаилә әгъзалары кебек, алар да үзләре эшләп тапкан малның (керемнең) билгеле бер өлешен бүлеп бирсеннәр. Үз акчаларын үзләре теләгәнчә туздыруга юл куярга ярамый.

Үз кирәк-яракларына тотылган кесә акчаларына килгәндә, аның күләме гаилә бюджетыннан чыгып билгеләнергә тиеш. «Фәлән үз баласына фәлән күләмдә акча бирә» дигән принциптан чыгып эш итәргә ярамый. Кесә акчаларын атнага яки айга бер тапкыр бирсәң хәерле. Бу әти-әни һәм балалар өчен дә отышлы. Әти-әни балаларны контрольдә тота алса, балаларга исә аңлап эш итәргә мөмкинлек тудырыла. Шул рәвешле, балалар гаиләнең керем һәм чыгымнарыннан хәбәрдар булып торалар.

Әти-әни балаларның финанс эшләренә турыдан-туры катышырга тиеш түгел, ләкин шулай да ара-тирә аларның үз акчаларын нәрсәгә сарыф иткәннәрен белешеп торырга кирәк. Балалар үз акчаларын транспортта йөрү, кесә телефоны өчен түләү, канцелярия кирәк-яракларына тотса хәерле була. Әгәр әти-әни кызының яки улының акчаны кирәксезгә сарыф итүен белсә, аларга аның бу хатасын йомшаграк формада аңлату тиешле. Әгәр инде болай хәл итеп булмаса, ул очракта аңа үз кирәк-яракларына дигән кесә акчаларын көн саен, ләкин аз күләмдә бирергә кирәк.



«Юрганыңа карап аягыңны суз!» дигән халык мәкале бар. Һәрберебез дә әнә шул мәкальне кагыйдә итеп алып, булганына Аллаһыга шөкер итеп, кергән малны дөрес итеп бүлеп һәм сакчыл карап яшәсәк иде. Ин шә Аллаһ.

■ **Лилия Җиһан**

# Тәрбия хакында – хәдисләрдә

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәләм: «Әти-әни баласына бирә алган иң күркәм әйбер – тәрбия», – дип әйткән.

Шулай ук икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Әти кеше өчен бала тәрбияләү, көн саен күп күләмдә садака биреп баруга караганда яхшырак».

Тагын бер хәдистә: «Тәкъва булыгыз һәм балаларыгыз арасына гаделлек белән эш итегез (аларның һәрберсенә дә бертигез игътибар бирегез һәм кайгырту күрсәтегез)», – дип әйтелә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәләм: «Дөреслектә, Кыяматтәге хөкем вакыты үткәч, җәннәттәге бер кеше үзе лаек булмаган дәрәҗәләргә күтәрелер. Ул шулвакыт: «Бу дәрәҗә миңа ни өчен бирелде», – дип гаҗәпләнер. Аңа: «Бу баланың синең гөнаһларыңны ярлыкауны сорап кылган догалары өчен», – дип җавап кайтарылыр», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше үлгәч, өч төрле гамәлдән кала калган гамәлләре өчен әҗер килүе туктый. Ул өч гамәл: әҗере бетми торган садака – садака җәрия, кешеләргә файда китерә торган гыйлем, аның өчен Аллаһы Тәгаләгә дога кылачак изге бала», – дип әйткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер бәдәви килә: «Әй, Пәйгамбәр галәйһиссәлам, сез балаларыгызны үбәсезме? Без үпмибез», – дип әйтә. Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәләм: «Аллаһы Тәгалә йөрәгегездәге рәхимлелекне алгач, мин ни эшли алыйм инде?» – дип җавап кайтарган.

Шулай ук бер хәдистә: «Кыз балалар тәрбияләп үстергән кешеләр, кызларына карата бик игътибарлы булырга, кайгыртырга тиешләр, чөнки кыз балалар аларны Кыямәт көнендә ут газабыннан саклаучы киртә булачаклар», – дип әйтелә.



# Җомга көненең фазыйләтләре



Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Әй, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә иман китергән бәндәләр! Җомга көнне намазга чакырган азан тавышын ишетү белән, бөтен эшне, сату-алу, дөнья мәшәкатьләрен калдырып, Аллаһыны зикер итәргә ашыгыгыз. Бу, әгәр белсәгез икән, сезнең өчен хәерлерәк. Намазларыгызны укып бетергәч, таралып Аллаһы фазылыннан ризык эзләвегезне дәвам итегез (эшләп), шулай гына морадларыгызга ирешерсез».**

«Җомга», 62:9-10

Көннәрнең иң бөеге һәм иң олысы – һичшиксез, җомга көнедер. Җомга көненең Аллаһы Тәгалә каршысындагы бөеклеге Корбан һәм Ураза гаетләреннән дә олырак. Бу көннең биш фазыйләте бар: «Бу көнне Адәм галәйһиссәлам яратылды, шул ук көнне ул җиргә төшерелде һәм шулай ук җомга көнендә вафат та булды. Бу көндә барлык догаларның кабул ителү сәгате бар. Кыямәт көне дә җомга көнендә булачак. Һавада, җирдә яки суда нинди генә җан иясе булмасын – һәрберсе җомга көненең олылыгыннан тетрәп калтырар». Бу вакыйгалар Ибне Мәҗәһ җыентыгындагы хәдистә риваять ителә.

## Җомга намазының әһәмияте

Җомга көн Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөэминнәрнең бәйрәме буларак кабул ителгән һәм ул көннәрнең патшасы. Шул сәбәпле җомга намазын уку өчен һәрбер мәхәлләдә – шәһәр һәм авылда булган кешеләр мәчеткә җыелып имамның хөтбәсен, вәгазен тыңлыйлар, мөселманнар үз араларында бер-берсе белән танышып, хәлләрен сорашалар, ике җомга арасында булган вакыйгаларга бәйле вәгазьләрне ишетеп, тәэсир алалар һәм бергә Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылып, ислам кардәшлеген яңарталар. Җомга намазы гаять әһәмиятле һәм файдалы. Моны игътибарга алмау һәм гозер булмый торып җомга көнне мәчеткә бармый калу – күңел каралудан башка нәрсә түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр бер кеше гозерсез өч җомганы калдырса, Аллаһы Тәгалә аның күңелен мөһерләп куя», – дип әйткән. Һәм икенче бер хәдистә: «Кем берninди сәбәпсез өч җомга намазын калдырса, шул безнең өммәттән түгел», – дип әйтелә.

Ә менә мәчеткә алдан беренче булып килүнең бик зур савабы бар. Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җомга көнне фәрештәләр мәчетнең ишек төпләрендә кешеләрне көтеп торырлар һәм беренче, икенче, өченче килгәннәрне язып барырлар. Шулай итеп, җомгага иртәрәк, беренче килүчеләр бер дөя чалган әҗер-савапка ирешерләр. Аннан соң килүчеләр бер сарык чалып, аны садака итеп өләшкән әҗер-савапка ирешерләр. Моннан соңрак килүчеләр – бер тавыклык әҗер-савапка, моннан соң килүчеләр тавык йомыркасын өләшкән әҗер-савапка ирешерләр».

Кем җомганың иртәнге сәгатьләрендә тәһарәт алып, мәчеткә җәяүләп килсә, аннары бер сүз дәшмичә вәгазь тыңлап, намаз укыса, аңа мәчеткә атлап килгән һәр адымы өчен бер еллык ураза әҗере (икенче бер хәдистә килә – һәр адымы өчен 20 еллык савап) язылыр. Һәм атлап килгәндә кешенең аяклары Аллаһы юлында тузанлану сәбәпле, Кыяміттә бу аякларны Аллаһы Тәгалә җәһәннәм утында яндыруны харам кылыр. Бу хәдисне Тирмизи җыентыгында укый алабыз.

Икенче бер хәдис имам Бохарида китерелә: «Кем җомга көнне госелләнеп, яхшы киемнәрен киеп һәм исле майлар сөртеп, этешмичә мәчеткә җомга вәгазен тыңларга килсә, имам минбәргә менеп, намазыннан аерылганчыга хәтле эндәшмичә хөтбәсен тыңлап, намазын укыса, аның ике җомга арасындагы гөнаһлары гафу ителер».

## Җәһәннәмгә күпер салма

Динебездә намаз гыйбадәтен беренче сафларда башкару бик саваплы эшләрдән санала. Ләкин мәчеткә соң килүчеләргә намаз уку өчен урынны беренче сафларда табу һәрвакытта да мөмкин булмый. Шуңа күрә дә мәчеткә иртәрәк килү хупланган эш булып санала, мәчеткә соң килеп, алгы сафка барам дип, башкаларга кыенлыклар тудыру – тыелган эшләрдән булып санала. Моның турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә әйтә: «Җомга хөтбәсенә соң килеп, кеше өстеннән атлап, аларга кыенлык тудыручылар үзләренә җәһәннәмгә илтә торган күпер салалар. Әгәр инде кеше намазга соңарып килсә, мәчет намазын һәм алдагы 4 рәкәгать сөннәт намазын укымыйча, тыныч кына имамның вәгазен тыңларга тиеш. Җомга көнне мәчетнең һәр ишегә алдына ике фәрештә килеп, җомгага килүчеләрне гамәлләр дәфтәренә чиратлап яза башлыйлар. Имам минбәргә чыгып, хөтбәсен укый башлагач, фәрештәләр дә дәфтәрләрен ябып, имамның хөтбәсен тыңлый башларлар. Инде мәчеткә килеп, диккать белән җомга вәгазен тыңлаган кешенең шушы җомга көннән алып, 10 көн эчендә эшләнгән кечкенә гөнаһлары кичерелер. Әгәр кеше башкаларга вәгазьне тыңларга комачаулап, сөйләшеп утырса, бу кешенең барча изгелекләре, намазлары бушка булыр. Моның хакында имам Мөслимнән хәдис китерелә: «Җомга хөтбәсе укыган вакытта яныңдагыңа «сөйләшмә» дип әйтсәң дә, гөнаһлы буш сүз сөйләгән булырсың».

## Догалар кабул була

Җомга көне эчендә бөтен догалар кабул булган бер сәгать бар, әмма бу вакытның кайсы сәгатьтә икәнен беркем белми, бу хакта галимнәр төрле фикердә. Чөнки бу хакта сигез сахих хәдис китерелә: «Җомга көне эчендә бер сәгать бардыр ки, бу сәгатьтә намаз укып, дога кылган һәрбер колның догалары Аллаһы Тәгалә тарафында һичшиксез кабул ителер».

Икенче бер хәдистә болай диелә: «Аллаһы Тәгалә «Бәйт Әл-Мәгъмур» урыны янында көмештән ап-ак манара бар кыла. Ул манараның биеклеге 500 еллык юл кадәрдер. Җомга көнендә Җәбраил галәйһиссәлам ул манарага чыгып азан әйтер. Исрафил галәйһиссәлам минбәрдән хөтбә-вәгазь сөйләр. Микаил галәйһиссәлам бөтен фәрештәләргә имам булыр. Намаз беткәч, Җәбраил галәйһиссәлам: «Мин азан укып алган савабымны дөньядагы азан укыган мөэминнәргә тапшырдым», – дип әйтер. Исрафил галәйһиссәлам: «Мин сөйләгән вәгаземнең савабын дөньядагы вәгазь сөйләүче мөэминнәргә тапшырдым», – дип әйтер. Микаил галәйһиссәлам: «Мин имам булып, намаз укытуымның савабын дөньядагы барча имамнарга тапшырдым», – дияр. Шуннан соң барча фәрештәләр: «Җәмәгать булып укыган намазның савабын дөньядагы җәмәгать булып намаз кылган барча мөэминнәргә тапшырдык», – дип әйтәләр. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә фәрештәләрдән: «Сез Миннән дә юмартракмы?» – дип сорап, Үзенең бу соравына җавап итеп дөньяда җомга намазын кылган мөэминнәрнең барча гөнаһларын кичереп, фәрештәләрдән күпкә юмарт булуын күрсәтә.

Пәйгамбәребезнең шундый сүзе бар: «Җомга көненең 24 сәгате эчендә Аллаһы Тәгалә 600 мең кешене җәһәннәм утыннан коткарып кала торган вакытны билгеләде. Бу пәнҗешәмбе көнне ахшам намазыннан башлап, җомга көненең соңгы намазына кадәр вакыт арасы». Кем белә, бәлки күп хәер догалар кылып, гөнаһларыбызны Аллаһы Тәгаләдән кичерүен сорап тәүбә итсәк, яшерелгән кичерелү вакытына туры килербез, һәм мәгъфурлардан, мәңгелегебез кичерелгән кешеләрдән булырбыз, ин шә Аллаһ!

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Без Аллаһы Тәгаләнең Китабын, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен, безгә гасырлар буе буыннан-буынга мирас булып килгән бөек Ислам динебезне үзебездән соң киләчәк яңа буын балаоныкларыбызга тапшырыйк.

■ **Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,**
**Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы**

## Җәмәгать намазында имамнан алдан рөкүгъ кылсаң, намаз бозыламы?

**Сорау: Әгәр җәмәгать намазы вакытында имамга кадәр рөкүгъ кылсаң, бу гамәл намазны бозамы? Әгәр инде тиз арада кыямга бассаң, үз намазыңны саклап кала аласыңмы?**

**Җавап:** Имам белән җәмәгать арасында ярашканлык булырга тиеш. Намаз вакытында җәмәгать имамнан алда хәрәкәтләр ясарга тиеш түгел, чөнки бу дөреслеккә туры килми. Хәтта кеше имамга кадәр рөкүгъ кылып, үз гамәлен аңлап, имам рөкүгъ кылганчы янәдән басып торган халәтенә кайтса да, аның намазы бозылган булып санала. Әгәр инде бу кеше имамнан алда рөкүгъ кылса, ә имам аның артыннан ук рөкүгъ кылса, шул рәвешле алар икесе дә рөкүгъ халәтендә булсалар, бу очракта имамга ияргән кешенең намазы бозылмас.

Мәсәлән, әгәр Коръәнне намазда укыган вакытта бер аятендә имам «Аллаһы» сүзен укыса, ләкин җәмәгатьтән берәрсе моны имам тәкбир әйтә дип аңлап, рөкүгъ кылса, ә имам әле укуын дәвам итсә, бу кешегә тиз арада кыямга басарга, ягъни элекке хәләтенә кайтырга кирәк. Әгәр инде ул кыямга басмаса, рөкүгъ, ягъни билдән бөгелгән халәтендә имамның рөкүгъ кылганын көтеп торса, бу очракта аның намазы бозылмый. Ничек кенә булмасын, имамга ияреп укыган очракта, иң дөресе булып җәмәгатьнең хәрәкәтләре имамның хәрәкәтләре белән тәңгәл килү тора.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,
Татарстан Республикасы мөфтие**

## Ислам дине һәм прививкалар



**Сорау: Исламда төрле авыруларга каршы прививкаларга караш нинди?**

**Җавап:** Вакцинация яки прививкалар ясату динебез кануннарына каршы килми. «Алдан чарасын күрү авырудан дәваланудан яхшырак» дигән гыйбарә мәгълүм.

Әмма вакцинация алдыннан организмга кертеләчәк препаратның составын тикшерү хәерле, чөнки анда Исламда тыелган матдәләр булырга мөмкин.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан
Республикасы мөфтие**

## Намазларны берләштерү рөхсәт ителәме?

**Сорау: Намазларны берләштерү ярыймы? Яраса, аларны кайчан берләштерергә?**

**Җавап:** Хәнәфи мәзһәбе буенча, намазларны берләштереп уку хаҗ вакытында бары ике урында – Гарәфәт тавында һәм Мөздәлифә үзәнендә генә ярый. Гарәфәт тавында өйлә намазы вакытында, өйлә намазы һәм икенде намазлары, ә Мөздәлифәдә ястү вакыты кергәч ахшам һәм ястү намазлары берләштерелеп укыла. Беренче очракта бу берләштерү «җәмгу-тәкъдим», ә икенче очракта «җәмгу-тахир» дип атала (мулла Гали Әл-Кари, Әл-Мәсләкул-Мутакассыт фил-Мәнсәкил-Мутавасыт).

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,
Татарстан Республикасы мөфтие**

## Интернет-кибет акчаны кире кайтарды...



**Сорау: Без интернет-кибеттә товар алып, карта белән түләдек һәм товарларны бирү ноктасында үз әйберебезне алдык. Бераз вакыт үткәч, «алынмаган заказ өчен» дигән хәбәр белән, картабызга акча кире кайтты. Без интернет-кибеткә товарны алуыбызны хәбәр итеп, акчаны ялгыш кайтаруларын аңлаттык. Безгә рәхмәтләр белдереп, барысын да ачыклап, кайтарылган акчаны алачакларын әйттеләр. Инде икенче ай узып бара, товар да бездә, акчасын да кире алмадылар. Бу очракта нишләргә?**

**Җавап:** Сезнең кебек намуслы мөселманнар булуына бик шатмын. Еш кына нәкъ алыш-биреш, сәүдә эшләре мөселманның ихласлыгын күрсәтеп тора.

Соравыгызга килгәндә, сезгә акчаны кибеткә кайтарырга кирәк, хәтта алар моны үзләре эшләмәсә дә. Вакыт-вакыт кибет белән элемтәгә кереп, үзегез турында искә төшереп торыгыз. Мөселманнар үз дин кардәшләре белән дә, башка дин вәкилләре белән дә намуслы булырга тиеш.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан
Республикасы мөфтие**

## Ике хөтбә арасындагы дога

**Сорау: Җомга намазында 4 рәкәгатьтән соң имам вәгазь укыгач догалар кылалар. Нинди дога укырга була?**

**Җавап:** Ике хөтбә арасында булсын, башка вакытта булсын, иң хәерле дога – Ахирәт өчен кылына торган дога. Әгәр дөнья мәнфәгате өчен дога кыласыз икән, теләгән нәрсә Ахирәткә зарар китермәсен дип дога кылырга кирәк була.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,
Татарстан Республикасы мөфтие**

## Проблемалардан арынсам, мин каза намазлары башкарырмын дип вәгъдә биргән идем...



**Сорау: Минем билгеле бер проблемаларым бар. Мин ул проблемалардан арынсам, каза намазлары кылырмын дип вәгъдә биргән идем, ләкин минем казага калган намазларым юк. Бу очракта миңа нишләргә?**

**Җавап:** Әгәр берәү ниндидер бер теләге үтәлгән очракта, ике рәкәгать намаз кылырга нәзер бирсә һәм теләгәне үтәлсә, ике рәкәгать намаз кылып, ул нәзерен үтәгән булып санала. Бирелгән нәзере бу кешегә һәрдаим ике рәкәгать намаз кылырга кирәклеген аңлатмый. Безнең кардәшебезнең соравында нәзер турында сүз баруын искә алсак, бер мәртәбә әйткән намазын кылган икән, ул моның белән вәгъдәсен үтәгән булып санала һәм үз өстеннән җаваплылыкны төшерә. Өстәмә намазлар башкару кирәкми.

Моннан тыш, нәзернең бер шарты – ул гыйбадәт булырга тиеш түгел, чөнки гыйбадәтне кеше болай да үтәргә тиешле. Мәсәлән, әгәр кеше: «Минем ниндидер эшем килеп чыкса, мин өйлә намазын укыячакмын» яки «Мин Рамазан аенда ураза тотачакмын», – дип әйтсә, аның әйткән нәзере дөрес булып саналмый. Әгәр бу сорауны биргән кардәшебезнең намазлары буенча бурычлары бар икән, ул аларны болай да кайтарырга (каза кылырга) тиеш. Шул сәбәпле аның әйткән нәзере дөрес булып саналмый.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,
Татарстан Республикасы мөфтие**

# Болгарда алтынчы тапкыр Мәүлид Ән-Нәби үткәрелде

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Болгарда алтынчы тапкыр Мәүлид Ән-Нәби оештырылды. Быел ул Болгар ислам академиясе бинасында үтте.




Мәүлид Ән-Нәбигә багышланган чаралар программасын «Ислам мәгарифендә заманча технологияләр: Татарстан Республикасында ислам мәгарифенең күп баскычлы системасы» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция ачып җибәрде. Фәнни форум, исламның традицион кыйммәтләрен саклау максатыннан, дини белем бирү системасы үсеше темасын ачып бирүгә багышланды.

Кунаклар һәм катнашучылар Ак мәчеттә икенде намазы укыганнан соң, шәех Исмәгыйль Бул-Бул вәгазен тыңлады.

«Мәүлид Ән-Нәби» кичәсе исә ахшам намазыннан соң, Болгар ислам академиясенең атриум залында башланып китте. Тантанада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының «Милли Шура» рәисе Васил Шәйхразиев, Болгар ислам академиясе Президенты Камил Исхаков, Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев, шулай ук танылган дин һәм дәүләт эшлеклеләре, Россия төбәкләре мөфтиләре – Коми, Дагъстан, Самара, ХМАО, Ульян өлкәләреннән, мөхтәсибләр һәм Татарстан мәдрәсәләре вәкилләре – барлыгы 300дән артык кеше катнашты.

Бәйрәм чарасы, традицион рәвештә, Коръән аятьләре укудан башланды. Шуннан соң сүз Васил Шәйхразиевка бирелде. Ул катнашучыларны, кунакларны Татарстан җитәкчелеге, Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән сәламләде һәм Мәүлид белән тәбрикләде.

«Без бүген кабат ата-бабаларыбыз Ислам динен кабул иткән изге җир – Болгарда Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең туган көнен билгеләп үтәргә җыелдык. Бүгенге җыен – безнең өчен зур горурлык та, өмет тә», – диде ул. ТР Премьер-министры урынбасары хәзерге көндә республикада мең ярым мәчет эшләвен, анда имамнарның халыкка хезмәт күрсәтүен искәртте. Ул яшьләрнең дин өлкәсендә эшләргә теләк белдерүләрен билгеләп, бүген Татарстанда дини белем алу өчен мәдрәсәләр, көллиятләр, университет һәм хәтта академия булуына игътибар юнәлтте.



Алга таба мөселман кардәшләребезгә сәламләү сүзләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөрәҗәгать итте.

Ул сөекле Пәйгамбәребезнең туган көне хакында: «Бу көн уңаеннан күп төрле фикерләр бар. Кайберәүләр Мәүлидне билгеләп үтүне кабул итмиләр. Алар Мөхәммәд Пәйгамбәр туган көнен үткәрмәгән, ди. Әмма Бохари җыентыгына карасак, Пәйгамбәребез дүшәмбе саен ураза тоткан. Ни өчен дигән сорауга ул: «Бу минем туган көнем», – дип җавап биргән. Димәк, ул аны шул рәвешле билгеләп үткән, ягъни бу көн гади генә көн түгел», – дип ассызыклады.

«Коръәни Кәримдә «Юныс» сүрәсендә: «Әгәр дә Раббыбыз сезгә бер юмартлык күрсәтсә, рәхмәт җибәрсә, мөэминнәр шуңа шатлансыннар», – диелә. Ягъни, Аллаһының әмере – бер рәхмәт килсә, без шатланырга тиеш. Ә рәхмәтләрнең иң зурысы – Пәйгамбәребезнең дөньяга килүе. Коръәндә әйтелә: **«Әй, Мөхәммәд, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек».** («Әнбия» сүрәсе, 107 нче аять). Билгеле, без бу рәхмәткә ихлас күңелдән сөенәбез», – диде Татарстан мөфтие.

Кунакларның рәсми сүзләре танылган нәшид башкаручылар Илгиз Шәйхразиев, Заур Салихов һәм «Саф» ансамбленең иҗади чыгышлары белән аралашып барды. Шулай ук татар телендә «Мәүлид Ән-Нәби» касыйдәсе укылды.

Республикабызның мәчетләрендә Пәйгамбәрнең дөньяга килүенә ихлас күңелдән шатлануны белдереп, ай дәвамында төрле чаралар үткәрелде. Алар Расүлебезнең тормышын өйрәнүне, аңа күпләп салаватлар әйтүне, Коръән аятьләрен уку, догалар кылу, вәгазьләр сөйләүне үз эченә алды. Мәүлид мәҗлесләре Пәйгамбәребез галәйһиссәлам узган юлны һәм аның сөннәт гамәлләрен искә төшерүне, аның күркәм әхлакый үрнәген өлгә итеп алуны, рухыбызны тәрбияләү һәм ныгытуны максат итеп куя.

■ dumrt.ru

# Мәрҗани турниры нәтиҗәләре: хаҗга юлламаны Чаллы көрәшчесе отты





16 ноябрь көнне Казанда билбау көрәше буенча күренекле татар дин галиме һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуга багышланган Халыкара турнир узды.

Турнирны ачу тантанасында ТР Спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов, Татарстанның билбау көрәше федерациясе башкарма директоры, билбау көрәше буенча Халыкара федерациянең генераль секретаре Хәбир Хәбибуллин, Үзбәкстан һәм Таҗикстанның билбау көрәше федерацияләре президентлары Равшан Дастиров һәм Әнвәр Касыймов, Россиянең көрәш федерациясе вице-президенты Равил Ногманов, Дагъстанның Татарстандагы тулы вәкаләтле вәкиле Мөхәммәд Мөслимов, Дагъстан мөфтие урынбасары Әхмәт Кахаев, Россия көрәш сәнгате берлегенең ТР буенча филиалы Башкарма комитеты җитәкчесе Александр Даренков, турнирның баш хөкемдары Рамис Вафин һәм башкалар катнашты.

Турнир ачылышына махсус кунак буларак Олимпия чемпионы, өч тапкыр дөнья чемпионы, ике тапкыр Аурупа чемпионы, Россиянең танылган спорт мастеры Абдулрәшид Садулаев чакырылган иде.

Быелгы турнирда Россия, Таҗикстан, Үзбәкстан, Казахстан көрәшчеләре катнашты. Россия данын исә ике команда – билбау көрәше буенча Татарстан Республикасы җыелмасы һәм Идел буе дәүләт физкультура, спорт һәм туризм академиясе җыелма командалары яклады. Спортчылар 62 кг, 68 кг, 75 кг, 82 кг, 90 кг, 100 кг, 100 килограммнан авыррак үлчәү категорияләрендә көч сынашты.

Ярыш нәтиҗәләре буенча Татарстан җыелмасы беренче урынга лаек дип табылды. Икенче урынны Үзбәкстан командасы яулады. Өченче урында – Таҗикстан җыелмасы. Җиңүче командага 105 мең сум, икенче һәм өченче урын алган командаларга 49 мең һәм 35 мең сум күләмендә акчалата бүләк тапшырылды.

Үз категорияләрендә беренче урын яулаган Татарстан спортчылары арасында төп бүләккә жирәбә үткәрелде. Аның шартлары буенча, спортчы ислам кануннарын үтәүче һәм моңа кадәр хаҗга бармаган мөселман булырга тиеш иде.

Шул рәвешле, жирәбә буенча турнирның иң олы бүләген – хаҗга юлламаны Яр Чаллы көрәшчесе Альберт Хәертдинов отты. 24 яшьлек егет 90 кг авырлык категориясендә җиңде.

# «Хозур» нәшрият йорты «Россия – Ислам дөньясы» СКТ рәисе премиясенә лаек булды

Ноябрь аенда узган «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең IV утырышында Татарстан Республикасы Президенты һәм төркемнең рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов «Россия – Ислам дөньясы» илкүләм премиясен тапшырды. 2018 елгы премия ияләренең берсе булып ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты танылды. Лауреат дипломы ТР мөфтие киңәшчесе, нәшрият йортының директоры Ришат Хәмидуллинга «Просто о главном» фильмы өчен тапшырылды. Әлеге фильм экстремизмга дини һәм милләтара низагларны профилактикалауга юнәлтелгән социаль роликларны берләштерә.

Дипломда фильмның «хакыйкый ислам турындагы белемнәрне тарату һәм арттыруга, Россия халыкларының үзара килешүчәнлеккә ирешүенә, дәүләт-конфессияләр мөнәсәбәтләрен гармонияләштерүгә әһәмиятле өлеш кертүе» хакында билгеләп үтелә. Фильм җәмгыятьтә традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалау максатыннан әзерләнгән. Бу мөфти Камил хәзрәт тарафыннан ТР мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше дип билгеләнде, аны «Хозур» нәшрият йорты гамәлгә ашыра.




Татарстан мөфтиятенең иң мөһим пропаганда чараларының берсе булып нәзарәтнең «Хозур ТВ» мөселман телеканалы санала. Ул «Таттелеком» ААҖ ярдәме белән тормышка ашты. Хәзер телеканал татар һәм рус телләрендә интернетта **huzurtv.ru** сайтында, Россиянең берничә төбәгендә кабельле тапшырулар режимында күрсәтә.

**dumrt.ru**

# Көндәлек эшләр гыйбадәт була аламы?



Хатын-кыз күпчелек вакытын өйдә уздыра. Өй җыештыру, ашарга пешерү, балаларны тәрбияләү – бу көндәлек эшләр бик күп вакытны таләп итә. Мондый шартларда гүзәл затларның өстәмә гыйбадәт кылырга, тирән гыйлемнәр алырга мөмкинлеге калмаска да мөмкин, һәм бу, әлбәттә, мөслимәләрне бик борчыган.

Бервакыт Әсма бинте Язидә исемле хатын-кыз Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына килеп: «Йә Расүлуллаһ! Мин сиңа мөслимәләр исеменнән мөрәҗәгать итәм. Дөреслектә, син – ир-атлар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә җибәрелгән пәйгамбәр. Күпчелек вакытыбызны без үз өйләребездә үткәрәбез. Без һәрвакыт үз вазифаларыбызны башкарырга тиеш: ирләребезне канәгатьләндерәбез, аларга балалар табабыз, йортларын карыйбыз. Шуңа да карамастан, алар, без башкара алмый торган гамәлләр кылып, Аллаһыдан күбрәк савап алалар. Алар биш вакыт намазны мәчетләрдә укый, авырып китүчеләрнең хәлләрен белешәләр, җеназа намазын укыйлар, хаҗ артыннан хаҗ кылалар. Алар хаҗга яки яуга чыгып киткәндә, без аларның байлыгын саклыйбыз, балаларын тәрбиялибез, киемнәр тегәбез. Безгә алар алган савапның өлеше булмасмы?» – дип мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәребез Әсмага: «Игътибар белән тыңла, ә аннан соң сине җибәргән хатын-кызларга шул сүзләрне тапшыр: әгәр хатын-кыз иренә буйсынса, ул риза булырлык итеп өйдәге эшләрне башкарса, ире Аллаһы Тәгалә каршында бар бурычларын үтәгәне өчен алган савап кадәрле савап алыр», – дип җавап кайтара. Бу сүзләрне ишеткәч, Әсма бинте Язидә шатлыгыннан «Лә иләһә илләллаһ! Аллаһу Әкбәр!» дип кабатлый-кабатлый кайтып китә.

Шул рәвешле, хатын-кыз өен җыештырган, ашарга пешергән өчен алган савабы иренең җәмәгать белән намаз укыган, җеназа намазы укыган, хаҗ вә гомрә кылганы өчен алган савапка тиң.

Янә берничә кыска хәдисне искә төшереп китик:

– «Хатын-кыз идән себергәндә зикер кылса, Изге Кәгъбә идәнен себергән кебек савап алыр».


– «Ир-ат өенә кайткач, хатыны аңа (тугры һәм чиста күңелле булган халәтендә) ашарына бирсә, 12 ел гыйбадәт кылган кебек савап алыр».

– «Әгәр хатын-кыз сыер (яки башка хайван) саугандa зикер кылса, аның өчен һәр хайван дога кылып торыр».

– «Хатын-кыз ипи (кабартма һәм башка шундыйлар) пешергәндә «Бисмилләһ» дип зикер кылып торса, аның бәрәкәте артыр».

Димәк, хуҗабикәнең көндәлек хезмәте гаиләсен тәмле ризыклар белән сыйлау, өен пөхтәлектә тоту гына түгел, ә Раббысына гыйбадәт кылу да була ала икән. Моның өчен бу эшләрне авырсынмый, зарланмый башкарырга, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булып, Аның һәм иренең ризалыгына ирешергә омтылып эшләргә кирәк. Чисталык, җан тынычлыгы булган өйгә рәхмәт фәрештәләре дә кереп, бу йортта бәрәкәт артыр.

# Иң гади сөннәтләр




Көндәлек тормышта кайбер гамәлләрне без билгеле бер рәвештә башкарырга өйрәнгән. Мисал өчен, татарларда өйгә уң аяктан керү, эшне «Бисмилләһ» белән башлау кабул ителгән. Еш кына без бу гамәлләрнең сөннәт икәнлеген һәм динебез белән тыгыз бәйләнгән булуы турында уйланмыйбыз да. Сөннәт гамәл дибез икән – димәк, бу гамәлләрне безгә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтеп калдырган һәм аларны үтәү савaплы була.

Мәчеткә уң аяктан гына керергә ярыймы? Юк, әмма уң аяктан керсәң, саваплырак булачак. Гайшә анабыз Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хакында мондый хәдис тапшырган: «Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһының рәхмәте вә сәламе булсын), мөмкин булганча, бар нәрсәне уң яктан башкарырга яраткан. Тәһарәт һәм госел алуны, чәч тарауны һәм аяк киемен киюне». Бу хәдистән күренгәнчә, Пәйгамбәребез көнкүрештәге гади генә эш-гамәлләрне дә уң яктан эшли башлаган: чәчләрен уң яктан тарый башлаган, аяк киемен башта уң аягына кигән.

Шулай ук Гайшә тапшырган мондый хәдис бар: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам уң кулын – чисталык һәм ризык өчен, ә сулын нәҗесләрдән пакьләнү һәм барлык чиста булмаган әйберләр өчен кулланган». Ягъни ашаганда без уң кул белән ашарга тиеш, сулы белән ярдәм итәргә генә мөмкин, ә пакьләнгәндә истинҗә, борыннан суны сеңгерү кебек гамәлләрне сул кул белән башкарабыз.

Башка бер хәдистә Аллаһының илчесе: «Берегез аяк киеме кисә, уң аяктан башласын. Ә салганда сулыннан сала башласын. Уңга беренче чиратта киелсен һәм иң ахырдан салынсын», – дип әйткән. Янә мондый хәдис бар: «Кием кигәндә һәм чистарынганда (тәһарәт һәм госел алганда) уңнан башлагыз». Күрәбез, киенү кебек гади генә бер гамәлне башкарганда да Пәйгамбәребезнең сөннәтен үтәргә һәм савап алырга мөмкин.

Шушы һәм башка хәдисләрдән чыгып, галимнәр яхшы, уңай гамәлләрне уңнан башкарырга һәм башларга киңәш итәләр. Болар тәһарәт һәм госел алу, кием һәм аяк киеме кию, мәчеткә һәм өйгә керү, тырнак кисү, ашау-эчү, чәч тарау, бәдрәфтән чыгу һәм башка шундыйлар булырга мөмкин.

Сул якка килгәндә, киресенчә, мәчеттән чыгу, аяк киемен яки киемне салу, бәдрәфкә керү кебек гамәлләр сул кулдан яки сул яктан башланырга тиеш.

Әгәр кемдер бу гамәлләрне сәламәтлеге, онытып яки башка сәбәпләр аркасында болай башкара алмаса, әлбәттә, гөнаһы булмаячак. Әйтелгәннәр сөннәт һәм аларны шулай башкару Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә ияру вә аңа охшарга тырышу булып тора. Ниятләребез дөрес булса, ин шә Аллаһ, савабы да булыр.

■ **Сәхифәне Хәсинә Гыйззәт әзерләде**

# Дини гыйбарәләр ни сөйли?

## «Бәрәкәллаһ» сүзенең тәрҗемәсе

«Бәрәкәллаһ» гыйбарәсе ике сүздән тора – бәрәкәт һәм Аллаһы. Гарәпләр бу сүзне берәр кешегә яки әйбергә бәрәкәт иңүен теләп әйтәләр. Ислам динендә дә ул шул максат белән әйтелә. Беренче өлеше, ягъни «бәрәкә» дигән сүз «бәрәкәт иңдерелсен», «бәрәкәтле итсен» дип тәрҗемә ителә. Шуңа да аны «Аллаһы Тәгалә бәрәкәт бирсен», «Аллаһы Тәгалә бәрәкәтле кылсын» дип әйтергә була.

Бу гыйбарә теләк гыйбарәсе булып санала. Кулланышта да берничә төрле вариантын очрарга мөмкин. Мәсәлән, «бәрәкәллаһу фикүм», «бәрәкәллаһу ләкүм», «бәрәкәллаһу галәйкүм». Тәрҗемә ягыннан килгәндә, аларның өчесен дә «сезгә Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте иңсен» дип әйтеп булыр иде.

Кайсысын кайда кулланырга дигән катгый таләпләр куелмаган. Шуңа күрә араларыннан күңелгә иң якынын алып, шул берсен генә дә әйтергә мөмкин. Иң мөһиме, чын күңелдән Аллаһыдан сорау булырга тиеш. Әгәр дә кеше берәр кешегә яки берәр әйбергә бәрәкәт иңүен теләп, «бәрәкәллаһу фикүм» дип кенә әйтсә дә, бу аның өчен җитәрлек була.

Инде аермасы нәрсәдә соң, дип соралса, түбәндәгечә җавап биреп булыр иде. Кешенең үзенә һәм аның сыйфатларына: гыйлеме, матурлыгы, тәҗрибәсе, тырышлыгы, көче, яхшылыгы, киң күңеллелеге турында сүз барганда «бәрәкәллаһу фикүм» дип әйтү кулайрак була.

«Бәрәкәллаһу ләкүм» гыйбарәсе кешенең машинасына, эшенә, гаиләсенә, балаларына карата әйтелә ала. «Бәрәкәллаһу галәйкүм» кешенең гомумән бар булган әйберсе, тормышы, аның кылган гамәлләре, якыннары белән мөгамәләсе бәрәкәтле булсын өчен әйтелә.

## Нәрсә соң ул бәрәкәт?

«Бәрәкәт» сүзе безгә гарәп теленнән кергән. Гарәпләрдә бу сүз ике төрле мәгънә астында кулланыла: 1) зур күләмле; 2) даимилек һәм какшамаслык. Бәрәкәт сүзенең асылында шушы мәгънә ята да инде. Берәр нәрсәгә карата «бәрәкәтле булсын» дип әйтәбез икән, димәк без ул әйбернең күп булуын, озакка җитүен сорыйбыз. Ә берәр кешегә бәрәкәт теләсәк, димәк без аңа яхшылык һәм ул яхшылыкның күләм ягыннан күп булуын һәм вакыт ягыннан бик озакка сузылуын телибез булып чыга.

Бәрәкәтнең безнең телдәге мәгънәсе – Аллаһы Тәгаләнең безнең эшләребез белән разый булып, аңа Үзенең рәхмәтен иңдерүе. Шуңа да, Аллаһы Тәгалә берәр аз нәрсәгә Үзенең рәхмәтен, бәрәкәтен иңдерсә, ул әйбер күп була. Күп булган әйбергә иңдерсә, ул әйбер бик файдалы булачак. Ә иң мөһим бәрәкәтләрнең берсе – ул бу дөньяда да, бакыйлыкта да Аллаһының ризалыгында яшәүдер.

Шулай итеп, берәр кеше эшкә урнашса, аңа теләгән бәрәкәт – ул бу эшнең файда китерә торган булуы, бу эшнең рәхәтлек китерә торган булуын теләү. Ризыкка бәрәкәт теләү – аның күп булуын һәм даими булып торуын, тәнеңә көчсихәт өстәлүне теләү. Кешегә бәрәкәт теләү – аның сау-сәламәт, итагатьле булуын һ.б. теләү булыр. Шуңа күрә сабый балаларны күрергә килгәндә, бу сүзләрне өйрәнеп килү бик мөһим санала.

## «Бәрәкәллаһу» сүзе кайчан әйтелә?

Бу сүзләрне кеше үзендәге яки кешедәге берәр төрле әйбер ошаган вакытта, берәр кешене күргәч, гаилә өчен теләк теләгәндә, кешенең берәр яхшы сыйфатын үстереп җибәрү өчен һ.б. әйтергә мөмкин. Шулай ук бу гыйбарә кешене күз тиюдән дә саклап кала ала, чөнки кешегә Аллаһының рәхмәтен теләп кылына. Ә андый кешегә күз тию ихтималы бик түбән була. Күз тию дигән әйбер бар һәм ул хак. Татар халкында да, башка халыкларда да күз тиюдән саклану чаралары бик күп булган. Югарыда сабый балаларны күрергә барганда шушы сүзне өйрәнеп килергә кирәк дип әйттек. Бу юкка гына түгел. Сабый балаларга күз тизрәк тия ала, шуңа да балаларга караганда «бәрәкәллаһу фиһ», ягъни «Аллаһым, аңа бәрәкәтеңне бир», дип әйтергә кирәк. Аллаһның рәхмәте булган кешегә, Аллаһы Тәгаләнең теләве белән күз тию булмас.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәллам: «Әгәр дә берәрегез үзендә, йә үзенең малында, йә үзенең кардәшендә ошаткан нәрсәсен күрсә, Аллаһы Тәгаләдән бәрәкәт иңүен сорасын, чөнки күз тию – ул бар нәрсә. Бу хәдистән күренгәнчә, әгәр дә кешегә берәр нәрсә ошый икән, ул үзенең шул ошаган нәрсәсен күз тиюләрдән алдан ук саклап куярга тиеш. Бу – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер сөннәте булып тора.

## «Сөбеханаллаһи» сүзенең тәрҗемәсе

«Бәрәкәллаһ» сүзе кебек үк «Сөбеханаллаһи» да ике сүздән тора. «Сөбехан» һәм «Аллаһы». «Сөбехан» гарәп теленнән «саф, керсез, кимчелексез, камил, барча хаталардан пакь һәм ерак» дип тәрҗемә кылына. Бу сүзне әйтүче кеше Аллаһы Тәгаләнең барча хаталардан пакь булганына, тискәре сыйфатлардан азат булганына һәм Аның барча исем-сыйфатлары да камил икәненә инанган була.

«Сөбеханаллаһи» сүзе татар теленә «Аллаһы Тәгаләне барча кимчелекләрдән пакь дип беләм» дип тәрҗемә кылына. Бу Аллаһыны мактау сүзләренең берсе. Без, гадәттә, намаздан соң «Сөбеханаллаһи», Әлхәмдүлилләһи, «Аллаһу әкбәр» дип, Аллаһыны мактап утырабыз. «Сөбеханаллаһи» шуларның берсе булып, тәсбих дип атала. Калган икесе тәхмид һәм тәкбир дип аталалар.

Тәсбих дип Аллаһы Тәгаләнең кимчелекләре юклыгын күрсәтә торган сүзләргә һәм гыйбарәләргә әйтелә. Мәсәлән:

**«Аны ару, талу һәм йокы тотмас, җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр анныкыдыр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:255

«**Аллаһыга җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел, ул Аллаһы дәрәҗәдә бик бөек һәм бик олуг».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:255

**«Һичнәрсәгә, һичбер мәхлүкъка ихтыяҗы юк бәлки һәр мәхлукъның хаҗәтен үтәүче Аллаһыдыр. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады. Вә һичкем Аңа тиң булмады».**

«Ихлас», 112:2-4

Бу аятьләр үзләре дә тәсбих булып торалар. Игътибар белән карасак, аларда Аллаһы Тәгаләнең тискәре сыйфатлары булмаганлыгы ассызыклана, димәк, Аллаһы Тәгалә камил, әмма без Аны берничек тә күз алдына китерергә тиеш түгелбез. Аллаһы Тәгалә армый, йокламый. Ул Көч һәм Куәт иясе. Ул «тумаган һәм тудырылмаган». Ул – «Әл-Әүвәл» һәм «Әл-Әхыйр».

Шулай ук тәхмид дигән төшенчә дә бар дип әйттек. Тәсбих – Аллаһы Тәгаләнең тискәре сыйфатлары булмаганны раслау булса, тәхмид – Аллаһы Тәгаләнең камил сыйфатлары белән Аны мактау була. Иң гади мисал булып «әлхәмдүлилләһ» тора. Шулай ук, Аллаһы Тәгалә Көч һәм Куәт иясе, Хәким, Ризыкландыручы, бар нәрсәнең Хуҗасы, Бөек, Җиңелмәс, Барлыкка китерүче, Гөнаһларны ярлыкаучы һәм яшерүче, бар нәрсәне Ишетүче, бар нәрсәне Күрүче дип әйтсәк, бу да тәхмид була.

## «Сөбеханаллаһ» дип кайчан әйтәбез?

Бу гыйбарә көндәлек тормышта бик еш файдаланыла. Гомумән, мөселман кешесенең телендә тәсбих белән тәхмид булуы гадәти күренеш. Сөбеханаллаһи сүзен әйтүнең бер очрагы – берәр төрле начарлык, гаделсезлек яки кимчелек күргәндә. Икенче очрагы – Аллаһы Тәгаләгә мактаулар, тәсбихләр әйтеп, зикер итү.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләне еш зикер итәргә куша. Шулай ук аның түбәндәге хәдисенә күз салсак, тәсбих белән тәхмиднең никадәр олуг сүзләр икәнен күреп булыр иде: «Ике төрле сүз бар. Алар тел белән әйтү өчен бик җиңел, (Кыямәт көне) үлчәвендә (изге гамәл буларак) бик авыр. Алар Әр-Рахман булган Аллаһыга бик якыннардыр: «Сөбеханаллаһи вә бихәмдих», «Сөбеханаллаһил-Газыйм» («Аллаһы Тәгаләне барча кимчелекләрдән пакь дип беләм һәм Аңа мактау булсын». «Аллаһы Тәгаләне барча кимчелекләрдән пакь дип беләм һәм ул Бөеклек Иясе»)». Хәдистән күренгәнчә, бу сүзләр өчен әҗер-саваплар бик күп. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Сөбеханаллаһи һәм әлхәмдүлилләһи сүзләре күк белән җир арасын тутыра», – дип әйтә. Ягъни савабы ягыннан күк һәм җир арасын тутыра алырлык бу сүзләр, безнең өчен савап җыярга менә дигән мөмкинчелек.

Аллаһы Тәгаләне искә төшерү – иң күркәм гамәл. Без Аллаһы Тәгаләне истә тотканда, Аллаһы Тәгалә дә безне Үзенең рәхмәтеннән ташламас, ин шә Аллаһ.

■ **Гәбделхәким Фәсхиев**

# Гарәп илләрендә үскән татар кызы

Хәдия Шәнгәрәева – Казахстанда үткәрелгән X нчы Халыкара яшь дизайнерлар фестивалендә I нче дәрәҗәле диплом яулап, Миланга путевка ала!

**– Хәдия, сезне иҗади уңышыгыз белән котлыйбыз! Сез чит илдә яшәп тә, шулай матур итеп татарча сөйләшәсез, бу бик күркәм күренеш! Сезнең белән якынрак танышып үтик әле.**

– Рәхмәт, дуслар!

Сүземне әтиемнән башлыйсым килә: мин Шәнгәрәев Исмәгыйль кызы булам. Без гаиләдә барлыгы 11 бала, мин өченчесе булып туганмын. Әлхәмдүлилләһ, без барыбыз да дүрт телдә камил сөйләшәбез – татарча, инглизчә, русча, гарәпчә. Әтием безне тәрбияләгәндә бик үтемле ике җөмлә әйтә иде, беренчесе менә болай яңгырый: «Мине ачуландырасыгыз килсә, русча сөйләшегез». Әтиемнең бер ачуланганын күргәнем булмады.

Мин үзем дә инде хәзер ике бала анасы, 7 һәм 3 яшьлек ике кызым бар һәм, әлбәттә, без гаиләдә дә, туганнарыбыз белән дә бер-беребез арасында туган телдә сөйләшәбез – бу безнең тәртип буенча шулай.

**– Белемегез буенча сез кем? Үзегездә дизайнер сәләтләрен кайчан ачтыгыз?**

– Минем Мәскәүдә дә ике ел укыган чагым булды, сезгә кызык булса инде. Күпчелек тормышым гарәп илләрендә узды. Мин экономист белгечлегенә укыдым. Дизайнер белемем әлегә юк… Бала чактан үземнең, әниемнең күлмәкләрен гел үзгәртеп кидем. Ниндидер детален сүтеп ала идем яки башкасын тегә идем. Курыкмыйча шулай экспериментлар белән яшим мин. Күпчелек күлмәкләрем үземнең эскиз буенча тегелгән, яки үзем теккән.

**– Хәдия, Татарстанда, Казанда еш буласызмы?**

– Бала чактан әтием безне Татарстанга берәр төрле чаралар булган саен җибәрә иде: без барырга телибезме, юкмы; ул лагерьләр, мөселман яшьләре форумы, бөтендөнья татар яшьләре форумнары, чемпионатлар булсынмы. Хәзерге акылым белән мин әтиемне аңлыйм һәм аның акыллылыгы белән тагын да ныграк соклanam! Ул бездә Татарстанга карата мәхәббәт тәрбияләгән, татар халкына якынрак булуыбызны, татар дөньясының чын-чыннан бер өлеше итеп хис итүебезне теләгән. Әлхәмдүлилләһ, бик зур рәхмәт сиңа, әтием!

**– Әниегез турында да бераз беләсе килә иде…**

–Әнием Мәрьям була, белгәнегезчә, ул – 11 бала анасы, бик зур йөрәкле кеше дип әйтәсем килә. Әнием минем иң якын дустым. Төрле хәлләр була ала һәм, беренче чиратта, мин әнием янына киләм һәм аның белән дөнья хәлләрен уртага салып чишәбез. Һәм шуны да әйтеп үтәргә кирәк: әнием Рәшидә абыстайның оныгы, Татарстанда дәү әнине белмәгән кеше юктыр – көчле, зәвыклы нәсел кешесе. Әтиемнең әтисе Каләметдин – советлар союзы вакытында хәзрәт булып эшләгән. Әтием ягыннан да, әнием ягыннан да көчле рухлы кешеләр булган һәм шушы энергетиканы мин бик тоеп яшим.

**– Ниниди хыялларыгыз бар? Киләчәктә үзегезне кайда күрәсез?**

– Киләчәгебез бары тик Аллаһы Тәгалә кулында гына инде. Милләтемә ярдәм күрсәтү теләгем бик зур, чөнки бүгенге тел проблемалары турында без ишетеп, күреп барабыз. Татар халкым узган тарихка кайта башласак, минем йөрәгем әрни, чөнки кешеләр үз вакытында гарәп имләсендә язган, ә бүген милләтебез ислам динебездән ерагая бара… Әйтеп бетермәдем сезгә, әтиемнең икенче үтемле җөмләсе: «Җир шарында 10 млн татар кешесе яши, бер генә татар кешесен үзегезгә таба алырсыз әле». Чыннан да, татар кешесе күп,ә телне белгән, динне үтәгән, гореф-гадәтләрне сакларга тырышкан яшьләр көннән көн азая бара, бу бик аяныч хәл.

Мин инде үз тарафымнан, татар кызы буларак, үземнең әдәбем белән, иҗади эшләрем белән милләтебез алдында җаваплылыкны тотып яшәргә тырышам.



**– Хәдия, ихласлыгың өчен рәхмәт, менә сине – татар кызын – үз коллекцияң белән Миланга чакырганнар, бу инде безгә горурлык, ә сезгә уңышлар теләп калабыз!**

– Әйе, җылы сүзләрегез өчен рәхмәт. Әлегә үзем дә ышанып бетә алмыйм, насыйп булса, моны Аллаһының зур рәхмәте итеп кабул итәчәкмен!

■ **Әңгәмәдәш – Ленария Мөслимова, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре**

# «Яшь вәгазьче» бәйгесе игълан ителә

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте IV Республикакүләм «Яшь вәгазьче» бәйгесен игълан итте.

Конкурс ике турда уза: сайлап алу һәм финал этабы.

Катнашу өчен татар телендә иркле темага вәгазь язарга кирәк. Вәгазьне үзең турында мәгълүматлар белән (яшәгән шәһәр, телефон, электрон адрес, белем алу, эш урыны) түбәндәге электрон адреска җибәрергә: muslimmol.rt@gmail.com. Эшләр 2018 елның 10 декабренә кадәр кабул ителә. Иң яхшы эшләр ачык конкурста катнашу өчен сайлап алыначак.

Конкурсның финал өлеше 2018 елның 26 декабрендә Алабуга шәһәрендә узачак. Чыгыш ясаучылар арасыннан өч җиңүче билгеләнәчәк. Конкурста катнашучыларга вәгазь сөйләр өчен 5-7 минут вакыт бирелә. Ярышта 17 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь кызлар һәм егетләр катнаша ала (имамнар, хәзрәтләр һәм мөгаллимнәр бәйгегә кертелми).

Конкурсантлар теманы ачуга, яңалыкка һәм идеяләрнең үзенчәлегенә (оригинальлегенә), телдән һәм язма сөйләмнең дөреслегенә, сөйләмнең темпына һәм аһәңенә (интонациясенә), аудиторияне тоемлавына карап бәяләнәчәк.



Призлы урынга ия булган җиңүчеләр кыйммәтле бүләкләр һәм катнашучы дипломы белән бүләкләнәчәк. Беренче урын алучыга – смартфон, икенче урынга – Pocketbook, өченче урынга – диск.

■ **dumrt.ru**

# Гайшә бинте Әбү Бәкер

## Гайшәнең гаиләсе

Гайшә бинте Әбү Бәкер дүртенче (бишенче) пәйгамбәрлек елында дөньяга килә. Әтисе – Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк, беренче мөселманнардан. Әнисе – Өмме Руман, Гайшә туганчы ук Ислам динен кабул иткән итагатьле хатын була. Әлеге күренекле ата-ана гаиләсендә Гайшә яхшы холыклы, әдәпле булып үсә. Әсма исемле апасы белән бик яшьләй Ислам динен кабул итә.

## Пәйгамбәр галәйһиссәламнең Гайшәгә өйләнүе

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм еш кына дусты Әбү Бәкер гаиләсенең хәлен белергә бара торган булган. Гайшә аның күз алдында бөтерчек кебек тере һәм зирәк кыз булып үсә.

Хәдичәне югалтканнан соң Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенә урын таба алмый. Барысы да аңа ничек авыр булганны күрәләр, ләкин берсе дә аңа өйләнергә тәкъдим ясарга җөрьәт итми. Ә Хәүлә бинте Хәким аның янына килеп: «Әй Аллаһының Илчесе, син өйләнергә теләмисеңме? Теләсәң – гыйффәтле кызга, теләсәң – хатынга. Гыйффәтле кызга килгәндә, ул синең сөекле дустыңның кызы – Гайшә бинте Әбү Бәкер. Икенчесе сиңа ышанган һәм ияргән – Сәүдә бинте Зәмга», – дип тәкъдим ясый. Пәйгамбәребез: «Аларны миңа яучыла әле», – ди.

Хәүлә бинте Хәким бу хәбәрне Әбү Бәкер йортына җиткерә. Кызның әтисе хәбәрне ишеткәч: «Кардәшенең кызына өйләнергә ярыймы?» – дип сораган. Аллаһының Илчесе: «Мин – аның кардәше, ул – минем кардәшем, без Исламда кардәшләр. Аның кызы минем хатыным булырга хаклы», – дип җавап биргән. Шуннан соң кызның әтисе ризалык биргән.

Яшь килен Пәйгамбәр мәчете янындагы Мөхәммәд галәйһиссәламнең йортына урнаша. Кияүгә чыгу белән Гайшә тормышында бернәрсә дә үзгәрми диярлек. Бары тик мәхәббәт һәм кайгыртучанлык кына өстәлә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам яшь хатынның теләкләрен аңлый һәм аларны үтәргә тырыша. Аларның икесенең бергәләп хәбәшиләрнең сөңге белән уйнаганнарын карап торганнары мәгълүм. Шулай ук алар бергәләп спорт белән дә шөгыльләнгәннәр.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Бервакытны мин Аллаһының Илчесе белән сәфәргә чыктым. Ул чакта мин гәүдәгә бик үк таза булмаган яшь кыз идем. Мөхәммәд галәйһиссәлам кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Шуннан соң мин аның белән йөгердем һәм алдан килдем. Ул миңа бернәрсә дә әйтмәде. Бераз үсеп гәүдәгә тазаргач, мин аның белән тагын сәфәргә чыктым. Бу юлы да Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Бу юлы йөгергән вакытта ул мине узды. Шуннан соң ул: «Бу тегеюлы узганың өчен», – диде һәм көлде» (Имам Әхмәд).

## Гайшәнең күркәмлеге

Гайшә киңкүңеллелек, талымсызлык һәм юмартлык белән аерылып торган. Ачлык һәм ярлылыкка сабыр иткән, чөнки күп вакытта атналар буе аның өендә мичкә ягылмаган, ягъни икмәк яки башка ризык пешерелмәгән. Пәйгамбәр галәйһиссәлам өендә су һәм хөрмә белән генә торганнар.

Гайшә бик юмарт булган. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган. Бервакыт ул ураза тоткан көнне аңа йөз мең дирһәм биргәннәр. Ул акчаны бүлгән дә, мохтаҗларга тараткан.

Гайшә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: «Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка хатынкызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый һәм һәрвакытта да җавап таба идек». Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 2210 хәдис тапшырган.

## Гайшәнең өстенлеге

Гайшәнең Пәйгамбәр галәйһиссәламнең башка хатыннарына хас булмаган ун өстенлеге булган:

1. Пәйгамбәр галәйһиссәлам аннан башка бер гыйффәтле кызга да өйләнмәгән.
2. Гайшәне аклап Аллаһы Тәгалә аять иңдергән.
3. Җәбраил фәрештә аның ефәк тукымадагы сурәтен Мөхәммәд галәйһиссәламгә күрсәтеп: «Аңа өйлән, ул – синең тормыш иптәшең!» – дигән.
4. Алар Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән бер савыттан госел коенганнар.
5. Гайшә аның алдында ятканда Пәйгамбәр галәйһиссәлам намаз укыган.
6. Гайшә белән булганда Пәйгамбәр галәйһиссәламгә вәхи иңгән.
7. Җәбраил фәрештә аңа сәлам җибәргән һәм ул – Пәйгамбәрнең җәннәттәге хатыны.
8. Пәйгамбәрнең башы Гайшәнең тезендә булганда Аллаһы аның җанын алган.
9. Пәйгамбәр галәйһиссәлам Гайшәнең чираты булган көнне җан тәслим кылган.
10. Пәйгамбәр галәйһиссәлам Гайшәнең өендә күмелгән.

## Гайшә радыяллаһу ганһәнең вафаты

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең үлем авыруы көчәйгәч, ул хатыннарын йөреп чыкканда: «Иртәгә кемдә булам? Берсекөнгә кайда булам?» – дип сорашып, Гайшәнең чираты кайчан җитәсен белергә теләгән. Аның хатыннары Пәйгамбәрнең әлеге омтылышын күреп, үз чиратларын Гайшәгә биргәннәр. Гомеренең ахырын Пәйгамбәребез галәйһиссәлам яраткан хатыны янында үткәргән.

Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән тугыз гына ел яшәп калган. Үзе Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафатыннан соң якынча илле ел яшәгән, башкаларны дингә, фикһка, әдәбиятка өйрәткән. Өммәтнең иҗтимагый һәм сәяси тормышында катнашкан.

Мөэминнәрнең анасы Гайшә бинте Әбү Бәкер һиҗри белән 57 нче елда, сишәмбе көн, Рамазанның унҗиденче төнендә 66 яшьтә вафат булган. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең башка хатыннары белән бергә Бакый зиратында күмелгән.

# Имам Нәвәви

Тулы исеме: Әл-имам, Әл-хафиз, Шәех әл-ислам Мөхйиддин Әбү Зәкәрия Яхья бине Шәрраф бине Мәр бине Хәсән бине Хөсәен бине Мөхәммәд бине Җумга бине Хәзәм Ән-Нәвәви.

Шушы исемнәргә килгәндә, Әл-имам – үзенең артыннан ияртеп баручы яки шушы мәхәллә белән җитәкчелек итүчене атаганнар; Әл-хафиз – Коръәнне яттан белгәне өчен; Шәех әл-ислам – Ислам динен күтәрүдә, таратуда зур урын алганы өчен; Мөхйиддин – динне тергезүче, динне терелтүче. Әлеге исем кешенең язган хезмәтләре (китаплары) дин өчен хезмәт иткән очракта бирелә. Яхья бине Шәрраф – үз исеме. Аннары җиде буыны искә алына. Ән-Нәвәви – кайсы җирлектә туганына карата бирелгән тәхәллүсе.

Имам Нәвәви 631 нче һиҗри елның мөхәррам аенда Нәвә авылында дөньяга килә. Мөселман гаиләсендә туып, кече яшьтән үк ислам тәрбиясе ала. 8 яшендә инде ул Коръәнне яттан өйрәнә, фикһка караган кайбер китапларны укып, башка иптәшләреннән аерылып тора.

Әти-әнисе Имам Нәвәвинең гыйлемгә хирыслыгын күреп, аны Димәшкътагы (Сүриянең башкаласы) «Дәрул-хәдис» мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Әлеге уку йортында ул 16 ел буе дин гыйлеме ала һәм 665 елда шул ук мәдрәсәдә остаз булып эшли башлый. Калган бөтен гомерен гыйлем алуга һәм гыйлем таратуга багышлый.

Имам Нәвәви ике тапкыр хаҗ кыла, Әкъса мәчетен зиярәт итә. 676 елда авырып китә һәм 45 яшендә вафат була.

Үзенең кыска, мөбарәк тормышында ислам динен үстерүгә зур көч куя. Аның һәр көне шушы гыйлемгә багышланган була. Гыйлем эстәү, гыйлем алу һәм бирү аның бөтен ихтыяҗларын: ашау-эчү, киенү, өйләнү хаҗәтләрен канәгатьләндерә. Аның ашаган ризыгы бик аз күләмдә һәм бик гади була. Галим кеше буларак, ул дөнья ләззәтләренә бирелми. Соңыннан, тулысынча үзен гыйлемгә багышлап, хәтта өйләнми, балалары да булмый.

Имам Нәвәви үзенең тормышында мөселманнар өчен бик күп файдалы китаплар тәкъдим итеп калдыра:

1. «Шәрх сахих Мөслим» (Имам Мөслим китабына шәрех).
2. «Рийаду әс-салихин» («Изгеләр бакчасы») китабы.
3. «Әл-әзкәр» («Искә төшерү») китабы.
4. «40 хәдис» китабы һ.б.ш.

Алар бик әһәмиятле, тирән дәлилле һәм аңлау өчен дә бик җиңел хезмәтләр. Имам Нәвәви гамәл кылучы һәм дә нәсыйхәт (киңәш) бирүче галим була. Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын.

■ **Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде**

## Ий Гомәр! Мин сиңа иярмим

Мөселманнарга җиңү алып килгән бер бәрелештән соң хәлифә Гомәр Әл-Хаттаб ганимәт малларын бүлә башлый. Әмма һәрбер мөселманга бер кечкенә тукыма кисәге генә туры килә. Гомәр Әл-Хаттаб тукымаларны таратып бетергәннән соң, улы Габдуллаһ аның янына килеп: «Бу тукыма кисәгенең бер файдасы да юк (ул кисәк бик кечкенә була). Шуңа да мин үземнекен сиңа бирим. Икесен кушып, үзеңә күлмәк тектерә алырсың», – дип әйтә. Хәзрәти Гомәр бу бүләкне кабул итеп ала һәм шул тукымалардан үзенә кием тектерә. Берничә көн үткәч, хәзрәти Гомәр мөнбәргә менеп, вәгазь сөйләргә тотына: «Әй мөселманнар! Мине тыңлагыз һәм иярегез». Шулвакыт бер сәхабә торып: «Әй мөселманнарның остазы! Мин сине тыңлый алмыйм. Син Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд юлыннан бармыйсың!» – дип Гомәргә каршы килә. Гомәр хәлнең нидә икәнен сорагач, бу кеше: «Син бер эшеңдә безгә карата гаделсез булдың. Ганимәт малын бүлгәндә, без һәрберебез кечкенә генә тукыма кисәге алдык. Әмма алар бернәрсәгә дә яраксыз. Ә үзеңә син күлмәк тектерерлек зуррак кисәк калып калгансың», – дип аңлатып бирә. Хәзрәти Гомәр сәхабәләр арасында утырган улын – Габдуллаһны чакырып чыгара. Габдуллаһ бине Гомәр җыелган сәхабәләргә үзенең өлешен әтисенә биргәнен сөйләп бирә. Бу аңлатманы тыңлаган сәхабә дә: «Хәзер дәвам итсәң була. Мин сиңа чын күңелдән ышанам һәм иярәм, әй, мөселманнарның остазы», – дип җавап кайтара.

## Пәйгамбәребез өйрәткән намаз

Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең сәхабәләре белән мәчеттә утырганда бер сәхабә тиз генә кереп, намаз кыла башлый. Пәйгамбәребез аның ни рәвешле намаз укыганын читтән генә күзәтеп тора һәм аңа намаз кылмаганын, яңадан укырга кирәклеге турында әйтә. Сәхабә намазын укый, ләкин Пәйгамбәребез аңа янә шул сүзләрен кабатлый. Бу хәл өченче тапкыр кабатлангач, сәхабә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән намаз кылырга өйрәтүен сорый. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләренә кабул булсын өчен ни рәвешле намаз кылырга кирәклеген аңлата: «Намаз кылыр алдыннан тәкбир әйтегез. Аннан соң Коръәннән сезгә җиңел булганны укыгыз. Шуннан соң рөкүгъ кылыгыз. Рөкүгъта үзегез җитәрлек дип санаган кадәр көтеп торыгыз. Аннан тураеп басыгыз. Аннан соң сәҗдә кылыгыз. Шулай ук сәҗдәдә вакытта да үзегез җитәрлек дип санаган кадәр көтеп торыгыз. Сәҗдәдән күтәрелеп, тураегыз һәм көтеп торыгыз, үзегез җитәрлек дип санаган чаклы көтегез. Шуннан соң янә сәҗдә кылыгыз һәм үзегез җитәрлек дип санаган хәтле көтеп торыгыз. Шул рәвешле намазны тәмамларсыз» (Бохари, Азан,122).

## Гөнаһка ике дирһәм дә җитә

Тәбигыйннәр чорында Мөхәммәд бине Сирин дигән кеше яшәгән. Бу кешенең тәкъвалыгына бар кеше таң кала торган була. Кайвакытларда ул кешеләр аңлап бетерми торган гамәлләр дә кыла алган.

Бервакыт бер кеше халык арасында ялган тарата. Аның сүзләре буенча, Ибне Сирин бу кешегә ике дирһәм тиеш икән. Бу хәбәр Ибне Сиринга җиткәч, Ибне Сирин ул акчаларны бирүдән баш тарта. Алар очрашкач, бу ялганчы акчаларны сорай. Ибне Сирин баш тарткач, ул аннан ант итүен сорый. Гадәттә, мөселманнар бик сирәк ант итәләр. Бу ялганчы да Ибне Сиринның ике дирһәм аркасында гына ант итмәячәгенә өметләнгән була. Әмма Мөхәммәд бине Сирин акча тиеш түгеллеген ант белән раслап бирә. Янәшәдәге кешеләр аптырап:

– Ий, Ибне Сирин, син ике дирһәм өчен ант итәсеңме? Син кичә үзеңдә туган шик аркасында 40 мең дирһәм алудан баш тарттың. Башка берәү булса, анда шик тумаган булыр иде, һәм ул акчаларны алган булыр иде», – дип әйтәләр.


Шулвакыт Ибне Сирин: «Әйе, ант итәм. Дөреслектә, мин аны харам акчалар белән ризыкланганын теләмим, чөнки мин бу акчаларның аңа харам икәнен беләм, – дип җавап кайтара. Шулай итеп, Ибне Сирин 40 мең дирһәмнең аңа тиешлегеннән шикләнеп, ул акчалардан баш тарта. Шул ук вакытта, бу кешегә 2 генә дирһәм белән булса да, гөнаһка бату юлын куймый.

## Сәламләүнең фазыйләте



Мөхәммәд галәйһиссәлам янына бер кеше килеп аны: «Әссәләмү галәйкүм» дип сәламләгәч, Мөхәммәд сәламгә җавап биргән һәм: «10», – дип әйткән. Икенче кеше килеп: «Әссәләмү галәйкүм вә рәхмәтуллаһ», – дип исәнләшкән. Мөхәммәд сәламгә җавап биреп: «20», – дип әйткән. Тагын бер кеше килеп: «Әссәләмү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ», – дип сәлам биргәч, Мөхәммәд бу кешегә дә җавап биргән һәм: «30», – дип әйткән. Шунда булган мөселманнар Пәйгамбәр галәйһиссәламнән «10, 20, 30» саннарының мәгънәсен аңлатып бирүен үтенгәч, ул: «Беренче кешегә – 10 савап, икенчесенә – 20, өченчесенә 30 савап язылды», – дип җавап биргән. Сәламләү сүзләреннән тыш, Ислам динендә сәлам бирүгә бәйле кайбер кагыйдәләр дә каралган, мәсәлән транспорт (машина) эчендәгеләр җәяүлеләргә, үтеп баручылар – утырганнарга, ялгыз кеше – җәмәгатькә, кечерәк яшьтәгеләр өлкәнрәкләргә беренче сәлам бирергә тиеш. Хәдистә: «Аттагылар – җәяүлеләргә, үтеп баручылар – утырганнарга, аз санлылар – күп санлыларга, балалар олыларга сәлам бирергә тиеш», – дип әйтелә. Хәдисләрдән Мөхәммәд балаларга сәламне беренче үзе биргәне дә билгеле. Мәсәлән, Әнәс риваять иткән бер хәдистә болай диелә: «Мөхәммәд бала-чагалар янынннан үтеп киткәндә, аларга сәлам бирә иде».

## Бу хәлифәдән фәрештәләр дә оялган




Бервакыт Гайшә радыяллаһу ганһә Мөхәммәд галәйһиссәлам белән бер бүлмәдә булганда, рөхсәт сорап, Әбү Бәкер килеп керә. Пәйгамбәребез таянган халәттә утырып тора иде. Әбү Бәкернең артыннан ук рөхсәт сорап, Гомәр Әл-Хаттаб та керә. Бераздан бүлмәгә Госман бине Гаффән дә керергә дип рөхсәт сорый. Пәйгамбәребез туры итеп утырып, Гайшә анабызга чыгып торырга куша. Госман радыяллаһу ганһе бүлмәгә кереп, берникадәр вакыт торганнан соң чыгып китә. Гайшә радыяллаһу ганһә бүлмәгә кереп, бу хакта сорарга була: «Йи, Аллаһының илчесе, син әтием Әбү Бәкер кергәндә дә, Гомәр радыяллаһу ганһе кергәндә дә урыныңны да үзгәртмәдең, миңа да чыгарга кушмадың. Әмма Госман радыяллаһу ганһе кергәндә син үзең дә төз итеп утырдың, миңа да чыгарга куштың. Ни өчен?»

Пәйгамбәребез бу сорауга: «Бу кеше янында фәрештәләр дә оялалар. Ничек инде андый кеше янында миңа оят булмаска тиеш ди? Аллаһы белән ант итәм, фәрештәләр Госманнан Аллаһы Тәгаләдән оялган кебек оялалар. Әгәр дә син Госман кергәндә бүлмәдә булсаң, ул бер сүз дә дәшмәс һәм башын да күтәрмәс иде», – дип җавап кайтара.

# Мөселман галимнәренең казанышлары

Мөселман галимнәре дөнья фәнен үстерүгә зур өлеш керткән. Мисал өчен, Ибне Синаның «Әл-Канун» китабы ислам дөньясында гына түгел, Ауропада да табиблык эшенең нигезе булып саналган. Моңа дәлил булып бу китапның 600 ел дәвамында Ауропа университетларында уку әсбабы булуы тора. Башка мисалларны да карап китик.

## Тыйб – медицина



Рази (864–925) беренче булып җил чәчәге һәм бизгәк авыруларын аерып чыгара һәм тасвирлый. Әхшәмседдин (1389–1459) микроблар барлыгын ачыклаган. Камбур Вәсим (1761 вафат) туберкулез микробын ачкан. Инде мең ел элек Ибраһим Җәссар (1009 вафат) махау авыруының (проказа) сәбәпләрен билгеләп, аны дәвалау ысулларын тәкъдим иткән. Ибне Хәтиб (1313–1374) ваба (холера) авыруының йогышлы булуын фаразлый. Аммар исемле мөселман галиме тугыз гасыр элек үк үзенә генә билгеле булган ысул белән күзләргә операция ясаган. Гали бине Габбас (994 вафат) ракка хирургик операция ясый. Ул язган «Китаб әл-мәлики» медицина энциклопедиясе бүгенге көндә дә әһәмиятлелеген югалтмаган. Беренче хастаханә 707 елда, Вәлид бине Габделмәлик хәлифә хакимлек иткән чорда ачыла.

## Әл-җәбер – алгебра



Мөселман галимнәре математика өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән. Бу казанышлар бүгенге көн галимнәрен дә сокландыра. Күренекле Ауропа галиме Жак Рислер: «Безнең Яңарышның (Ренессанс) математика остазлары булып мөселманнар тора», – дип әйткән. Алгебрага нигез салучы Хәрәзми (780–850) беренче булып ноль санын кулланган. Ул «Әл-Җәбер вә әл-мөгабилә» дип аталган беренче алгебра китабы авторы да. Шушы «Әл-Җәбер» сүзе көнбатыш галимнәре әйтелешендә үзгәреп, «алгебра» булып китә. Беттани (858–929) тригонометриягә нигез сала. Әбүл-Вафа (940–998) тригонометриягә тангенс, котангенс, косинус төшенчәләрен кертә. Насреддин Түси (1201–1274) – тригонометрия буенча язылган беренче төпле фәнни хезмәтнең авторы. Тригонометриядә үзгәрмә зурлыкны Ибне Юныс (1009 вафат) керткән. Икебуын формуласын Ньютон керткән дип саналса да, беренче булып аны Гомәр Хәйәм (1123 вафат) кулланган.

## Йолдызлар турында гыйлем – астрономия

Мөселман галимнәрен бик кызыксындырган тагы бер фән – астрономия (гөлүмен-нөҗүм). Ислам дәүләтләренең зур шәһәрләренең һәрберсендә диярлек обсерваторияләр булган. Аларда мөселман галимнәре гасырлар дәвамында фәнни тикшеренүләр алып барып, күп серләр ачкан. Бу ачышлар исә Джордано Бруно (1546–1601), Коперник (1473–1543), Галилей (1564–1642) кебек күренекле галимнәрне илһамландырган. Мөселман галимнәре астролябияне (йолдызларның урынын билгеләү, алар арасындагы араны үлчәү өчен җайланма) камилләштергән. Зәркали (1029–1087) ул вакыт өчен иң төгәл һәм уңайлы астролябия уйлап чыгарган. Мөселман галимнәре Ауропа галимнәреннән күпкә иртәрәк Җирнең шарсыман булуын һәм әйләнүен фаразлаган. Бируни Җирнең үз күчәре һәм Кояш тирәли әйләнүен дәлилләгән. Һиндстанның Нандана шәһәре янында үткәргән тикшеренүләре нигезендә бу галим Җир шарының мәйданын санап чыгара алган. Бу ысул бүгенге көндә дә «Бируни кагыйдәсе» дип атала. Әл-Фирганинең астрономия өлкәсендәге хезмәтләре 700 ел дәвамында Ауропада уку әсбабы буларак кулланылган. Ул Кояшта таплар барлыгын да ачыклаган. Билгеле хаким Олугбәк (1394–1499) гомерен фәнгә багышлаган. Сәмәркандта ул зур обсерватория төзетеп, үз чорының бөек астрономы буларак танылган.



## Физика


Исмәгыйль Әл-Җәзари (1206 вафат) «Китаб әл-һиләл» хезмәтендә кибернетикага нигез сала. Оптикага нигез салучы Ибне Хәйсәмнең (965–1051) «Китаб әл-мәназир» хезмәте Роджер Бэкон (1214–1294), Кеплер (1571–1630) һәм Леонардо да Винчи (1452–1519) кебек галимнәрнең эшчәнлегенә этәргеч булып тора. Бу хезмәт 600 ел дәвамында фән дөньясында төп чыганаклардан саналган. Ибне Герәре (1100 вафат) беренче булып кыру станогы кора. Ибне Фирнәнәс 880 елда аэропланга охшаган беренче аппарат эшли. Бу корылма өчен ул кош каурыйлары һәм тыгыз тукыма кулланган. Ул озак кына вакыт һавада очып тора һәм салмак кына җиргә төшә. Көнбатышта аэропланда беренче тапкыр 1903 елда гына очалар әле.

## Химия

Химия турында сүз чыккач, иң беренче булып искә Җәбир бине Хәйян төшә. Аның химия өлкәсендәге хезмәтләре Пристли (1733–1804) һәм Лавуазьен (1743–1794) кебек галимнәрнең ачышларыннан да кыйммәтлерәк. Джордано Бруно аны дөньяның даһилары (генийлары) рәтенә кертә. Үзенең махсус лабораториясендә фәнни тикшеренүләр үткәреп, Җәбир күп серкәләрне (кислота) ачыклый ала. Искә алынган Рази күкерт кислотасын һәм чиста спиртны таба. Бәшир исемле мөселман галиме Ауропалы Бранттан бераз алданрак фосфорны ача. Беренче булып дары һәм пушканы да мөселманнар кулланган. Кысылган һава көче белән эшли торган пушканы солтан Мәхмәт (1432–1481) уйлап таба.

## Җәгърафия – география

Мөселман галимнәре җәгърафиянең фән буларак җитешүенә дә зур өлеш кертә. Җир шарының төрле почмакларын өйрәнгән Әүлия Челәбинең (1611–1682) һәм бар кыйтгаларда булып кайткан Ибне Батутаның (1304–1369) сәяхәтнамәләре бик кыйммәтле тарихи һәм географик хәзинәләр булып торалар. Күп гасырлар элек Бируни Американың барлыгын фаразлаган. Васко де Гаманың (1450–1554) сәяхәтләрендә юл күрсәтүче булып мөселман диңгез сәяхәтчесе Ибне Мәҗид Идриси (1100–1166) торган. 850 ел элек бүгенге көн харитаrange=0



таларына (карталарына) бик якын дөньяның географик харитасы төзелә.

## Табигать гыйлеме

Ибне Байтар (1190–1248) исемле галим, Урта гасырларда күренекле үләннәр белгече һәм фармацевт, үзенең китабында 1400 дару үләне һәм үсемлегенә тасвирлама бирә. Бу хезмәт әлеге өлкәдә иң әһәмиятле фәнни чыганак булып торган. Дамири атлы галим (1349–1405) «Хәятүл-хаявән» («Хайваннар яшәеше») дигән хезмәтендә хайваннар дөньясы хакында төгәл мәгълүматлар туплый.

Беренче кәгазь җитештерү фабрикасы Багдадта 794 елда Һарун Әр-Рәшиднең улы Ибне Фазыл тарафыннан төзелә. Шундый ук фабрикалар Мисырда 800 елда һәм 950 елда Әндалуста (Испания территориясе) төзелә. Ауропада мондый фабрикалар күпкә соңрак барлыкка килә: Византиядә – 1100 елда, Сицилиядә – 1102 елда, Алманиядә — 1228 елда, Бөекбританиядә – 1309 елда.

**Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшинның «Россиядә Ислам тарихы» китабыннан тәрҗемә**

## «Хозур» нәшрият йорты китап сату нокталарын арттыра

Габдулла Тукай урамы буенча урнашкан 36 йортта «Хозур» нәшрият йортының тагын бер китаплар сату ноктасы ачылды. Бу кибеттә дә Ислам буенча бик күп традицион дини әдәбият тәкъдим ителә.

Бүгенге көндә «Хозур» нәшрият йорты китаплары халык арасында киң тарала, китапларның төрлелеге көннән-көн арта бара һәм аларның һәрберсе Татарстан Диния нәзарәтенең голәмәләр шурасы тарафыннан тикшерү уза.

Сатуда төрле дини сорауларга җавап бирерлек фәнни китаплар, гарәп теле өйрәнүчеләр өчен дәреслекләр, дини-фәлсәфи китаплар, татар дин әһелләренең хезмәтләре дә бар. Басмалар күбесенчә ике телдә – татар һәм рус телләрендә чыга. Төрле яшьтәге, төрле гыйлем дәрәҗәсендәге кешеләр дә бу кибеттә үзләренә кирәкле китапны табыр, дип ышанып калабыз.

Габдулла Тукай, 36 нчы йорт буенча урнашкан «Хозур» нәшрият йорты кибете көн саен иртәнге 9 дан алып, кичке 6 га кадәр эшли.

Китаплар турында тулырак мәгълүматны huzurshop.ru сайтында табарга мөмкин.



«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42

## КАЗАН ӨЧЕН ДЕКАБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.12.2018 | 05:31 | 06:18 | 07:48 | 12:00 | 13:27 | 15:16 | 17:11 |
| 02.12.2018 | 05:32 | 06:19 | 07:49 | 12:00 | 13:27 | 15:15 | 17:10 |
| 03.12.2018 | 05:33 | 06:21 | 07:51 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:10 |
| 04.12.2018 | 05:35 | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 |
| 05.12.2018 | 05:36 | 06:24 | 07:54 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 |
| 06.12.2018 | 05:37 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 13:24 | 15:12 | 17:08 |
| 07.12.2018 | 05:38 | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:08 |
| 08.12.2018 | 05:39 | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:08 |
| 09.12.2018 | 05:40 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:23 | 15:11 | 17:08 |
| 10.12.2018 | 05:41 | 06:31 | 08:01 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 11.12.2018 | 05:42 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 12.12.2018 | 05:43 | 06:33 | 08:03 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 13.12.2018 | 05:44 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 14.12.2018 | 05:45 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 15.12.2018 | 05:46 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 16.12.2018 | 05:46 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 17.12.2018 | 05:47 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 18.12.2018 | 05:48 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:09 |
| 19.12.2018 | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:24 | 15:10 | 17:09 |
| 20.12.2018 | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:09 |
| 21.12.2018 | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:10 |
| 22.12.2018 | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:10 |
| 23.12.2018 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:11 |
| 24.12.2018 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:12 |
| 25.12.2018 | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:12 |
| 26.12.2018 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:13 |
| 27.12.2018 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:14 |
| 28.12.2018 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:29 | 15:16 | 17:14 |
| 29.12.2018 | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:30 | 15:17 | 17:15 |
| 30.12.2018 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:31 | 15:18 | 17:16 |
| 31.12.2018 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:32 | 15:19 | 17:17 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Ноябрь саны, №11 (280)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2755
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 29 нчы ноябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 28 нче ноябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.